РОССИЯ ФЕДЕРАЦИЯСЕ МӘГАРИФ ҺӘМ ФӘН МИНИСТРЛЫГЫ

**КАЗАН (ИДЕЛ БУЕ) ФЕДЕРАЛЬ УНИВЕРСИТЕТЫ**

ТӘРҖЕМӘ БЕЛЕМЕ ҺӘМ МӘДӘНИЯТАРА БАГЛАНЫШЛАР БҮЛЕГЕ

**ГОМУМИ ЛИНГВИСТКА ҺӘМ ЛИНГВОКУЛЬТУРОЛОГИЯ КАФЕДРАСЫ**

# ЧАГЫШТЫРМА ТЕЛ БЕЛЕМЕ
**(татар һәм рус телләре материалында)**

КАЗАН 2012

УДК 81'44 : (811.512 + 811.161.1)
ББК 81.2 Тат : 81.2 Рус
Ч 12

«Казан (Идел буе) федераль университеты»
югары һөнәри белем бирү дәүләт мәгариф учреждениесенең
Редакцион-нәшрият советы

Филология һәм сәнгать институты укыту-методик советы
(14 сентябрь, 2012 ел, 1 нче номерлы беркетмә)

гомуми лингвистика һәм лингвокультурология кафедрасы
(28 июнь, 2012 ел, 11 нче номерлы беркетмә)
карары белән басыла

Т ө з ү ч е
**М.Р.Саттарова**, филология фәннәре кандидаты, доцент

Ф ә н н и м ө х ә р р и р
**Р.Р.Җамалетдинов**, филология фәннәре докторы, профессор

Р е ц е н з е н т л а р
**Э.Н.Денмөхәммәтова**, филология фәннәре кандидаты, доцент (КФУ)
**И.Җ.Едиханов**, филология фәннәре кандидаты,
өлкән укытучы (КФУ)

**Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләре материалында).** Югары уку йортлары өчен укыту-методик ярдәмлек / Төз.: М.Р. Саттарова. – Казан: КФУ, 2012. – 60 б.

Әлеге укыту-методик ярдәмлектә татар һәм рус телләренең фонетик, сүз ясалышы, грамматик үзенчәлекләре чагыштырылып бирелә. Ул дәүләт белем стандартының 050302 “Туган (татар) тел һәм әдәбият” белгечлеге буенча югары уку йортларының көндезге бүлегендә укучы студентларга адреслана. Бу ярдәмлек шулай ук тәрҗемә белеме, журналистика белгечлекләре алучыларга, рус мәктәпләрендә татар телен укытучыларга һәм башкаларга файдалы булыр дип ышанабыз.

# КЕРЕШ

“Чагыштырма тел белеме: татар һәм рус телләре” курсы *050302 “Туган (татар) тел һәм әдәбият”* белгечлеге буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәр арасында үзенчәлекле урын алып тора. Ул студентларның уку барышында татар, рус телләреннән теоретик һәм гамәли курсларда туплаган белем-күнекмәләренә таянып оештырыла.

Курсның төп эчтәлеге чагыштырыла торган телләрнең типологик характеристикасына бәйле, телнең барлык ярусларына да кагылышлы универсаль, специфик һәм уникаль үзенчәлекләре хакында фәнни фикерләр, теоретик материал тасвирлаудан гыйбарәт. Курс шулай ук студентларны лингвистик терминология белән коралландыруны, чагыштырма тел белеме өлкәсендәге төп юнәлеш һәм мәктәпләр белән таныштыруны, татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм анализлау методларын өйрәтүне дә күз алдында тота. Өйрәнелә торган теоретик материалны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен, тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатыннан һәм гамәли дәресләр дә үткәрү планлаштырыла.

«Чагыштырма тел белеме: (татар һәм рус телләре)» курсыннан укыту-методик ярдәмлек татар филологиясе бүлегендә белем алучы студентлар өчен төзелде. Ярдәмлек лекция һәм гамәли дәресләрнең тематик планын, гамәли дәресләрдә анализлау өчен тәкъдим ителә торган тел материалларын, мөстәкыйль үзләштерү өчен темаларны, әдәбият исемлеген, имтиханга әзерләнү өчен якынча сораулыкны, укытучы һәм студент өчен методик киңәшләрне үз эченә ала. Тәкъдим ителә торган ярдәмлектә теоретик материал чагыштырма аспектта карала, аерым сорауларга бәйле өстәмә мәгълүмат бирелә. Белем һәм күнекмәләрне системалаштыру, гамәли әзерлекне нәтиҗәлерәк итү максатыннан тестлар һәм чагыштырма анализ ясау үрнәкләре да китерелә.

Шартлы билгеләр:

**?** – гамәли дәрес өчен сораулар

◊ – гамәли дәресләр өчен биремнәр

**!?** – мөстәкыйль үзләштерү өчен сораулар

## КУРСНЫ ӨЙРӘНҮ ӨЧЕН ЯКЫНЧА ТЕМАТИК ПЛАН

| т/б № | КУРСНЫҢ БҮЛЕКЛӘРЕ | Лекцияләр | Гамәли дәресләр | Мөстәкыйль эш | Барлыгы |
|---|---|---|---|---|---|
| 1. | “Чагыштырма тел белеме: татар һәм рус телләре” курсына кереш. Тәрҗемә. | 2 | 2 | 6 | 10 |
| 2. | Татар һәм рус телләре фонетикасы, лексикологиясе. | 4 | 4 | 6 | 14 |
| 3. | Чагыштырыла торган телләрдә сүз төзелеше, сүз ясалышы; исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, бәйләгеч һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре. | 6 | 6 | 8 | 18 |
| 4. | Татар һәм рус телләрендә фигыль. | 4 | 2 | 8 | 15 |
| 5. | Татар һәм рус телләре синтаксисы. | 4 | 2 | 8 | 15 |
| | **Барлыгы** | **20** | **16** | **36** | **72** |

## ЛЕКЦИЯЛӘР ҺӘМ ГАМӘЛИ ДӘРЕСЛӘР ӨЧЕН ТЕМАЛАР

### Тема 1. “Чагыштырма тел белеме: татар һәм рус телләре” курсына кереш. Тәрҗемә

1. “Чагыштырма тел белеме: татар һәм рус телләре” курсының эчтәлеге, максаты, бурычлары.

2. Татар һәм рус телләрен чагыштырма-типологик өйрәнү.

3. Чагыштырыла торган телләрнең типологик үзенчәлекләренә күзәтү.

4. Телләрне чагыштырма өйрәнү һәм тәрҗемә.

**?**

1. Бер телдән икенчесенә тәрҗемә итү принциплары. Тәрҗемә һәм чагыштырыла торган телләрнең типологик үзенчәлекләрен бирү мөмкинлекләре.

2. Татарстан Республикасында икетеллелек һәм күптеллелек шартларында дәүләт телләре һәм башка телләрнең кулланылыш үзенчәлекләре.

3. Икетеллелек, күптеллелек мәсьәләләрен хәл итүдә телләрне чагыштырып өйрәнүнең роле.

4. 2004-2013 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасының гамәлгә ашырылуы мәсьәләсе.

**!?**

1. Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законын һәм 2004-2013 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасын укырга, аларның республикадагы дәүләт телләрен чагыштырма аспектта өйрәнүдә әһәмиятен анализларга.

## Тема 2. Татар һәм рус телләре фонетикасы

1. Чагыштырыла торган телләрнең фонетик системаларын өйрәнү тарихы.

2. Татар һәм рус телләре фонетикасында универсаль, специфик һәм уникаль күренешләр: вокализм, консонантизм, иҗек.

3. Татар һәм рус телләрендә басым.

4. Орфографик принциплар.

**?**

1. Татар һәм рус телләрендә редукция күренеше.

2. Тел белем фәнендә сүзләрне иҗекләргә бүлү белән бәйле карашлар: динамик һәм сонорлык теориясе.

◊

1. Чагыштырма фонетик анализ ясагыз:

*бар (имеется) – бар (небольшой ресторан); казан – казан (котелок); келәт – клеть; чәйнек – чайник; хәлвә – халва;*

2. Сүзләрне төрләндерегез һәм басым характерын билгеләгез. Татар телендә: *капка, төлкедәй, һичкем, ниндидер, тутырма*; рус телендә: *сыр, величина, эффект, фазан, девять*.

**!?**

1. Чагыштырыла торган телләрдә ассимиляция, диссимиляция. аккомодация күренешләре.

## Тема 3. Чагыштырыла торган телләрнең лексикологиясе

1. Семасиология.

2. Татар һәм рус телләренең сүзлек составы.

3. Этимология, этимологик анализ принциплары, чыганаклар.

4. Фразеологик берәмлекләрне төркемләү принциплары, аларның семантик, лексикографик һәм грамматик үзенчәлекләре.

5. Татар һәм рус телләрендә сүзлекләр.

**?**

1. Татар һәм рус телләрендә сүзлекләрнең төрләре, аларны төзү принциплары.

2. Татар телендә кулланыла торган рус һәм рус теле аша кергән алынма берәмлекләрнең фонетик, морфологик һәм лексик-семантик үзләштерелеше.

◊

1. Аерым мисаллар ярдәмендә алынма берәмлекләрнең үзләштерелешен аңлатыгыз: *адрес, бүрәнә, врач, кәбестә, минут, мичкә, почта, сука, техник, цирк, эскәмия*.

2. Рус телендәге татар-төрки алынмаларының үзләштерелеше. Мисалларга нигезләнеп аңлатыгыз: *алтын, атаман, башмак, бешмет, изюм, казна, капкан, кетмень, чапан, ярлык*.

**!?**

1. Татар һәм рус телләрендә фразеологик берәмлекләр: тәрҗемә итүдә, сөйләмдә кулланылыш үзенчәлекләре.

2. Татар телендә парлы сүзләр кулланылышы, аларны рус теленә тәрҗемә итү.

**Тема 4. Чагыштырыла торган телләрдә сүз ясалышы**

1. Татар һәм рус телләрендә сүз төзелеше, морфемаларның төрләре, үзенчәлекләре.

2. Сүзләр ясалышы ысулларына чагыштырма характеристика.

**?**

1. Татар һәм рус тел белемнәрендә сүз ясалышына бәйле фикерләр.

◊

1. Бирелгән сүзләрне төзелеше ягыннан чагыштырма аспектта анализлагыз: *затлыландырырга – облагораживать, классташ – одноклассник, колбиләүчелек – рабовладение, никахланырга – жениться, очучы – летчик, сокландыргыч – очаровательный, суүсем – водоросль, төрлеләндерергә – разнообразить, шыксызландырырга – обезображивать, яланаяк – босоногий.*

**!?**

1. Татар һәм рус тел белемнәрендә сүз ясалышы ысулларына бәйле хезмәтләргә күзәтү.

**Тема 5. Татар һәм рус телләре грамматикасы.**

1. Татар һәм рус телләрендә грамматика төшенчәсе, төп терминнар.

2. Өйрәнелә торган телләрдә сүзләрне төркемләү мәсьәләсе.

**?**

1. Татар һәм рус телләре грамматикалары тарихына күзәтү.

2. Сүзләрне төркемләү принциплары.

3. Татар һәм рус телләренең орфографик принциплары.

**!?**

1. Хәзерге татар һәм рус тел белемнәрендә сүзләрне төркемләүгә нисбәтле фикерләр.

## Тема 6. Чагыштырыла торган телләрдә исем сүз төркеме.

1. Татар һәм рус телләрендә исем сүз төркеме, исемнәрнең семантик үзенчәлекләре.

2. Чагыштырыла торган телләрдә исемнәргә хас универсаль, уникаль категорияләр.

**?**

1. Татар телендә исемнәрнең килеш белән төрләнеше.

2. Рус телендә исемнәрнең килеш белән төрләнеше үзенчәлекләре.

3. Чагыштырыла торган телләрдә исем сүз төркеменә кергән лексик берәмлекләрнең ясалыш үзенчәлекләре һәм мөмкинлекләре.

◊

Исемнәргә чагыштырма анализ ясагыз: *бала – дитя, байрак – знамя, күршеләремнең – (моих / своих) соседей, күзлегемне – (свои / мои) очки, тартмалар – ящики, урындыкларны – скамейки, хәбәрләр – вести, хәтфәдән – бархатное / из бархата, (аның) чакматашы – (его / у него) кремень.*

**!?**

1. Чагыштырыла торган телләрдә исемнәрнең сыйфат белән кулланылышы үзенчәлекләре, җөмләдә функциональ мөмкинлекләре.

## Тема 7. Татар һәм рус телләрендә сыйфат, сан, рәвеш, алмашлык сүз төркемнәре.

1. Сыйфатларның семантик, морфологик һәм синтаксик билгеләре.

2. Татар һәм рус телләрендә сан сүз төркеме: семантик, грамматик билгеләре.

3. Татар һәм рус телләрендә рәвешләрнең үзенчәлекләре.

4. Чагыштырыла торган телләрдә алмашлык сүз төркеме.

**?**

1. Татар һәм рус телләрендә сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең үзенчәлекләре. Аерым берәмлекләр мисалында сыйфат һәм рәвеш сүз төркемнәренең кыен очракларын анализларга.

2. Рус телендәге сан сүз төркеменә кергән берәмлекләрнең килеш белән төрләнеше.

3. Чагыштырыла торган телләрдә алмашлыкларны төркемләү мәсьәләсе.

◊

1. Сүзләргә чагыштырма грамматик анализ ясагыз: *башлангыч – исходный, яшьрәк – моложе, чуп-чуар – пестрый-пестрый, хәбәрсез – бесследно, эчпошыргыч – монотонный; өчтән бер (өлеше) – одна третья (часть), утызынчы (елларда) – в тридцатые (годы); җиде-сигезләп – (около) семи-восьми, беренчеләрдән (булып) – первыми, меңләгән – тысячи; беркайчан да – никогда,*

*үзенең (әти-әнисе) – своих (родителей), кем дә булса – кто-нибудь; бушлай – бесплатно, яшьләй – смолоду, кинәт – внезапно.*

**!?**

1. Татар телендәге изафә конструкциясен рус теленә тәрҗемә итү.

2. Татар һәм рус телләрендә сыйфат, рәвеш, сан сүз төркемнәренең сүз ясалышы үзенчәлекләре.

## Тема 8. Татар һәм рус телләрендә аваз ияртемнәре, хәбәрлек сүзләр. Бәйләгеч һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре.

1. Татар һәм рус телләрендә аваз ияртемнәренең үзенчәлекләре.

2. Чагыштырыла торган телләрдә хәбәрлек сүзләр.

3. Бәйләгеч сүз төркемнәре: бәйлекләр һәм теркәгечләр.

4. Модаль мәгънәле сүз төркемнәре.

**?**

1. Татар һәм рус телләрендә теркәгеч / союз, бәйлек / предлог сүз төркемнәренә кергән берәмлекләр белдергән мәгънә мөнәсәбәтләренә чагыштырма аспектта анализ ясау.

**!?**

1. Татар һәм рус телләрендә модаль сүзләр, аларның функциональ үзенчәлекләре.

## Тема 9. Татар һәм рус телләрендә фигыль.

1. Затланышлы һәм затланышсыз фигыль формалары.

2. Татар һәм рус телләрендә фигыль сүз төркеменә хас уникаль, специфик һәм универсаль грамматик категорияләр.

**?**

1. Рус телендә фигыльгә хас вид категориясенең татар телендә бирелеше.

2. Татар һәм рус телләрендә фигыль нигезе.

3. Татар телендә фигыльләрнең модальлеге аша белдерелә торган мәгънәләрне рус телендә бирү мөмкинлекләре.

◊

1. Фигыльләргә чагыштырма грамматик анализ ясарга: *чумырырга – черпнуть, күрсәтермен – буду показывать, әйткән идегез – говорили (как-то / когда-то / было), (кунакка) килә торганнар иде – приходили (в гости), эшләмәсәң – (если) не будешь работать, (китап) сатып йөрүче – продающий (книги), җемелди торган – мерцающие, йотлыга-йотлыга – захлёбываясь.*

**!?**

1. Рус телендә фигыль класслары, әлеге бүленешнең әһәмияте.

## Тема 10. Татар һәм рус телләре синтаксисы.

1. Татар һәм рус телләрендә сүзләр бәйләнеше, сүзтезмә.
2. Җөмләнең грамматик, логик-семантик, синтагматик һәм актуаль кисәкләре.
3. Чагыштырыла торган телләрдә гади җөмлә төрләре.
4. Татар һәм рус телләрендә гади кушма җөмләләр.
5. Татар һәм рус телләрендә катлаулы кушма җөләләр.

**?**

1. Татар һәм рус телләрендә җөмләдә сүз тәртибенең үзенчәлекләре.

◊

1. Бирелгән җөмләләрне рус теленә тәрҗемә итегез һәм сүзләрнең җөмләдәге урынын чагыштырып анализлагыз.

*1.1. Камилә белән Руслан университетта яхшы укыдылар. Камилә белән Руслан яхшы университетта укыдылар.*

*1.2. Әлеге күргәзмәне китапханә хезмәткәрләре бу атнада оештырдылар. Бу атнада әлеге күргәзмәне китапханә хезмәткәрләре оештырдылар. Бу атнада китапханә хезмәткәрләре әлеге күргәзмәне оештырдылар.*

*1.3. Солы кыры... Байый кояш.*
*Кайтам кичен, соңлап, урап;*
*Артта гомер-кишәрлек җир,*
*Ята кырда сынган урак (С.Хәким).*

2. Җөмләләрне тәрҗемә итегез, бәйләүче чараларга нисбәтле төрен билгеләгез.

*2.1. Болытлар таралды, һәм көн матурланды. Яңгыр бик каты яуганлыктан, ул көнне көлтәләр сугарлык булмады (М.Мәһдиев). Кем эшләми, шул ашамый (М.). Җәмил ишегалдында күренүгә, лапас күләгәсендә утырган Фирүзә фыр итеп күтәрелде, тырылдап өйгә кереп китте, китабын өйалды идәненә ыргытты да чабып кире әйләнеп чыкты (А.Гыйләҗев).*

*2.2. У широкой степной дороги, называемой большим шляхом, ночевала отара овец (А.Чехов). Утро, когда начинается этот рассказ, наступило пасмурное, но теплое (К.Паустовский). К утру третьих суток дождь снова хлынул потоками, оглушительно бил гром, сверкали страшные синии молнии, а на рассвете тучи точно рукой смахнуло, и на чисто вымытом небе празднично расцвело удивительно яркое солнце (М.Горький). Дед оказался прав: к вечеру пришла гроза (К.Паустовский). В груди кипело, жег душу огонь (В.Шишков). Что касается меня, то я во время уроков чаще всего читал интересные книжки (В.Солоухин).*

3. Тәкъдим ителгән мисалларга нигезләнеп, татар һәм рус телләрендә җөмләнең баш кисәкләренә чагыштырма анализ ясагыз.

*3.1. Язмыш – аяусыз нәрсә (А.Гыйләҗев). Башта “инсульт” диделәр. (А.Гыйләҗев). Тәвәккәл таш яра (М.). Атларны чабышка әзерлиләр. Ул имтиханга әзерләнә булса кирәк. Икенче төркем отличниклардан тора. Мин – студент. Бу китап Алсуныкы. Тормыш дәвам итә. Ул як-ягына күз салды. Һәрбер хатын-кызның сере була, ә сер берчакта да тик ятырга яратмый, аның тизрәк юл аласы, дөньяга чыгасы килә (А.Гыйләҗев).*

*3.2. – Это ты, Дим?*

*– Я, – ответил Волков. – Спи. (Кунин)*

*Сто пятьдесят лет назад, 18 августа 1851 года, из Петербурга отправился первый поезд. (Коняев). С опытным проводником не страшно ничего (Федосеев). Жизнь человека сложна и многослойна, есть в ней пики и спады, есть зоны совершенно запретные (П.Проскурин). Был случай, который должен был насторожить все подразделения (Федосеев).*

4. Оештыручы үзәккә бәйле җөмләләрнең төрләрен билгеләгез.

*4.1. Бүген минем бер дә ялгыз каласым килми. Безгә кичә үк барырга иде. Күршеләрдән калышасы түгел иде. Уңыйсызрак төшелде ахры. Кыш. Буран. Көзге җил. Тышта җил, яңгыр (Ә.Еники).*

*– Безгә кил әле.*

*– Ярар.*

*Ну, йокланылган да соң төнлә. Чак торылды (М.Мәһдиев).*

*4.2. Утро было свежее и прекрасное. Прошло несколько лет. Что посеешь, то и пожнешь (посл.). Вечереет. Ничего не слыхать. А вот и порт, толпой судов заставленный, и рынок здешний, до небес прославленный, с его египетского хлопка кипами, со звоном денег, с криками и всхлипами, с его торговцев языками бешеными, как колокол над городами подвешенными (К.Симонов). Мальчик ничем никогда не болел и никогда не простужался. Две двери вели из прихожей (Белов). Вскоре я бросил писать стихи (К.Паустовский). Поздно ночью небо расчистило (Белов). Отвезешь обратно на пристань (К.Паустовский). В двери дуло (К.Паустовский). Между бабьим «да» и «нет» не проденешь иголки (посл.). Опять в лесу захрустело отчетливо и ясно (А.Серафимович). К этому было не привыкать Григорию (М.Шолохов).*

**!?**

1. Татар һәм рус телләрендә сүзтезмәләрнең мәгънә мөнәсәбәте ягыннан үзенчәлекләрен чагыштырыгыз.

## ЧАГЫШТЫРМА АСПЕКТТА ТЕОРЕТИК МАТЕРИАЛ
## ТИПОЛОГИЯ

Татар теле – агглютинатив (тагылмалы) тел. Монда грамматик мәгънә белдерүдә аналитик чаралар өстенлек итә.

Рус теле исә флектив һәм бу телдә грамматик мәгънә белдерүдә синтетик чаралар өстенлек итә.

## СУЗЫКЛАР СИСТЕМАСЫ – ВОКАЛИЗМ

| **рәт / ряд** \ **күтәрелеш / подъем** | **телләр** | **алгы / передний** | **урта / средний** | **арткы / задний** |
|---|---|---|---|---|
| **югары / верхний** | т | **и ү** | | **ы у** |
| | р | **и** | **ы** | **у** |
| **урта / средний** | т | **э э (ĕ) ө** | | **ы (ы) о (ō) о** |
| | р | **э (е)** | | **о** |
| **түбән / нижний** | т | **ә** | | **а°** |
| | р | | **а** | |

*Татар һәм рус телләрендә [а], [ы], [о], [э], [и]* авазлары, сузыклар редукциясе специфик күренешләр булып санала. Татар телендә *тулы редукция* кыска сузык сонант янында басымсыз ачык иҗеккә туры килгәндә, *өлешчә редукция* ябык иҗекләрдә күзәтелә; рус телендә басым алдындагы иҗектә һәм калган басымсыз иҗекләрдә нигездә [а], [о], сирәк кенә [э] авазлары кыскара, авазның сыйфаты үзгәрә.

Сузык авазларның калын һәм нечкә парлары булу: *а – ә, у – ү, о – ө, ы – е, и – парсыз;* озын (*а, ә, у, ү, и*) һәм кыска (*о, ө, ы, е) әйтелешлеләргә бүленүе;* ирен һәм рәт гармониясе; [ә], [ө], [ү] сузыклары татар теленә генә хас.

## ТАРТЫКЛАР СИСТЕМАСЫ – КОНСОНАНТИЗМ

| ясалу урыны / ясалу ысулы | | | телләр | ирен-ирен (губно-губные) | ирен-теш (губно-зубные) | тел алды / теш (зубные) | аңкау-теш (небно-зубные) | тел уртасы (средненебные) | тел арты (задненебные) | увуляр | фарингаль | ларингаль | акустик аспект |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| йомык (смычные) | шартлаулы (взрывные) | т | б-п | | д-т | | | г-к | қ | | ء | шаулылар / шумные |
| | | р | б-б' п-п' | | д-д' т-т' | | | г-г' к-к' | | | | |
| | аффрикат | т | | | ц | ᵗч | | | | | | |
| | | р | | | ц - | -ч' | | | | | | |
| ярык / өрелмәле (щелевые) | ике фокуслы | т | | | | ж ш щ | | | | | | |
| | | р | | | | ш-ш' ж-ж' | | | | | | |
| | бер фокуслы | т | | в-ф | з-с | җ-ч | | х' | ғ х | һ | | |
| | | р | | в-в' ф-ф' | з-з' с-с' | | j | х-х' | | | | |
| | | т | w | | | | й | | | | | сонорлар / сонанты |
| ярымйомык (смычно-проходные) | борын (носовые) | т | м | | н | | | ң' | ң | | | |
| | | р | м-м' | | н-н' | | | | | | | |
| | ян-як (боковые) | т | | | л | | | | | | | |
| | | р | | | л-л' | | | | | | | |
| калтыраулы (дрожащие) | | | | | | р р-р' | | | | | | |

Ике телдә дә тавыш һәм шау катнашуга карап, тартык авазлар яңгырау, саңгырау, сонор төрләргә бүлеп карала. Чагыштырыла торган телләрдә *[х], [ч]; [в], [ц], [щ]* авазлары, тартыкларның яңгыраулык һәм саңгыраулык ассимиляциясе специфик күренеш булып тора.

Борын, ирен һәм кече тел ассимиляцияләре; тартыклар аккомодациясе; [ғ], [к], [w], [һ], [ж], [ң], [ء] авазлары кулланылу татар теленә генә хас. Тартыкларның фонематик мәгънәгә ия калын һәм нечкә вариантлары булу рус телендә генә күзәтелә.

## ИҖЕК

Ике телдә дә сузык аваз иҗек ясый; иҗек бер сузыктан гына яки бер сузык + бер яки берничә тартыктан торырга мөмкин; иҗек басымлы да, басымсыз да була ала; ачык һәм абсолют ачык, ябык, каплаулы (прикрытый) һәм каплаусыз (неприкрытый) була.

Иҗек калыпларының төрләре, саны үзенчәлекле күренеш буларак карала.

Татар телендә бер иҗектә рәттән ике яки берничә тартык килә алмый. Килгән очракта да ике тартыкның берсе сонант була һәм иҗек кими баручы яңгырашка ия.

Рус телендә бер иҗектә бер-бер артлы 4 тартык, алгы рәт сузыклары белән калын тартыклар, арткы рәт сузыклары белән палаталь тартыклар килә ала.

## БАСЫМ

Ике телгә дә: сүз басымы (*ике яки күп иҗекле сүздә бер иҗекне аеру*), синтагма яки такт басымы (*синтагма эчендә мөһим мәгънә белдерүче сүзне аеру*), фраза басымы (*сөйләмдә мөһимрәк булган такт / синтагманы аеру*), логик (*җөмләдә аерым сүзнең мәгънә әһәмиятен аеру, шул сүзгә игътибар юнәлтү өчен*) һәм эмфатик басым (*җөмләдә аерым сүзне эмоция белән әйтү*) хас.

Фонетик аспектта татар һәм рус телләренә көч (динамик, экспиратор) басымы хас; ләкин татар теле өчен сүз басымының әһәмияте рус телендә кебек түгел, басым көчсезрәк табигатьле; рус телендә басымлы иҗек көчлерәк һәм озынрак әйтелә.

Морфонологик аспектта ике телдә дә басым хәрәкәтчән һәм тотрыклы булырга мөмкин, бу басымның даими яки ирекле булуы белән бәйле түгел; вариатив, төп һәм өстәмә басым була.

Аермалыклар: татар телендә сүз басымы даими, кагыйдә буларак, сүз ахырына төшә; алынма берәмлекләр, кушма сүзләр һәм аерым сүз формалары бу кагыйдәдән чыгарылма булып тора. Рус телендә сүз басымы ирекле, сүзнең төрле урынында килә ала.

## ЛЕКСИКОЛОГИЯ

Татар һәм рус телләренең лексикологиясе *семасиология, этимология, фразеология, лексикография* бүлекләреннән тора.

**Семасиология**. Ике телдә дә сүзләрнең түбәндәге мәгънә төрләре аерып карала: *номинатив / сигнал; төп (прямое, основное) / күчерелмә (переносное); конкрет / абстракт; терминологик / гомуми; образлы / образсыз; эмоциональ / эмоциональ булмаган*. Сүзнең төп мәгънә белән беррәттән өстәмә мәгънәгә дә ия булуы *күпмәгънәлелеге – полисемия* дип атала. Беренчел мәгънәләр туры, икенчел мәгънәләр күчерелмә дип карала. Күчерелмә мәгънәле сүзләр *фразеологик бәйле* (билгеле бел сүзләр белән кулланылганда гына нәтиҗәле) һәм *синтаксик бәйле* (контекст белән бәйле аңлашыла торган күчерелмә мәгънә) була.

Лексик мәгънәләрнең үзара бәйләнешендәге аермаларга мөнәсәбәтле рәвештә сүзләр – *синонимик, антонимик, монолексик* (*бер ук сүзнең төрле сүзләр белән бәйләнешкә кергән вакытта туган мәгънәләре*) / *омонимик; мотивлашкан (мотивированное, производное от первых – туры мәгънәдән чыгып кына аңлап була)* / *мотивлашмаган (немотивированное, непроизводное – сүзнең беренчел мәгънәсе, башка мәгънәләр белән бәйле түгел); нигез* / *ясалма; ирекле* / *бәйле; вакытлы* мәгънәләргә аерылалар.

Сүзләрнең күчерелмә мәгънәләренең төрләре: *метафора* – охшашлык нигезендә атама күчүе: *балык тәңкәсе – тәңкәләр чыңылдый, теплое течение – теплое участие* һ.б.; *метонимия* – әйбернең янәшә торуы нигезендә барлыкка килгән күчерелмә мәгънә: *якты аудитория – аудитория игътибар белән тыңлый, люстра из бронзы – старинная бронза*; *синекдоха* – сүз мәгънәсе бөтеннән өлешкә, өлештән бөтенгә күчү: *язу карасы, бушлаты с бескозырками*. *Катахреза* күренеше – сүзләрнең беренчел мәгънәләре югалып, «сәер» мөнәсәбәтләргә керүе: *кара аккош, ак кер, кара кер бергә юылмый, вишневый лимонад, красные чернила*.

*Омонимнар:* саф лексик (полные или абсолютные) – *бит (йөз) – бит (кисәкчә), ключ (ачкыч) – ключ (чишмә);* омоформалар – *печь (мич) – печь (пешерү), үпкәләр (легкие) – үпкәләр (күңеле калыр);* омофоннар – *Айтуган – ай туган, лук – луг, род – рот* (рус телендә фонетик омонимнар дип тә атала); омографлар – *бал (мед) – бал (бию кичәсе), мука – мука (он).*

*Синонимнар:* абсолют: *бегемот – гипопотам, җиһан – дөнья;* идеографик (мәгънәви): *мөһим – актуаль – әһәмиятле, горячий – жаркий – жгучий – знойный – обжигающий – палящий;* стилистик: *тез чүгү – буйсыну, лицо – рожа һ.б.*

*Антонимнар* мәгънә ягыннан бүленә.

Татар телендә: күренеш, предмет, кеше сыйфатлары (ак – кара); вакыт төшенчәсе (иртә – кич); күренеш озынлыгы, күләме (озын – кыска); табигать күренешләре (аяз-болытлы); процесс (бару – кайту); гомумирәк төшенчәләр (яшәү – үлем).

Рус телендә: сыйфатлау (хороший – плохой); тоемлау (мокрый – сухой); күләм, үлчәм (толстый – тонкий); авырлык (тяжелый – легкий); форма (острый – тупой); төс (белый – черный); психологик билге (добрый – злой); вакыт (ранний – поздний); пространство (близкий – далекий) һ.б.

Шулай ук исем (мир – война), сыйфат (большой – маленкий), фигыль (отдыхать – работать), рәвеш (рано – поздно), предлог (в – из, под – над) антонимнарны аерып карау да бар.

**Этимология.** Сүзләрең килеп чыгышын барлаганда өч *принцип* нигез булып тора:

фонетик – тарихи фонетика, сүздәге тарихи аваз тәңгәллекләрен өйрәнә;

сүз ясалышы – телдәге суффиксларның продуктив, продуктив булмаган төрләрен билгели, тере, үле төрләргә бүлә;

семантик – сүз мәгънәләренең мөнәсәбәтләре, семантик һәм семасиологик закончалыклар белән эш итә. Иң катлаулыдан санала. Күпмәгънәлелек игътибарда тотыла, кайбер очракларда күчерелмә мәгънә төп мәгънәгә әйләнергә мөмкин.

Этимологик анализ өчен *чыганаклар*: сүзлекләр һәм матур әдәбият; фразеологизмнарның аерым элементлары; фольклор; кардәш телләр; башка телләр; язма истәлекләр.

*Энантиосемия* – сүздә капма-каршы мәгънәләрнең үсеше. Мәсәлән, исле сүзендә уңай – хуш ис, капма-каршы – яман ис мәгънәләре бар; наверное – наверняка / вероятно. Бу күренеш кардәш телләр арасында ешрак очрый.

Сүзнең беренче мотивировкасы югалу, кисәкләргә таркала торган сүзнең таркалмый торганга әйләнүе (сүзнең эчке формасы югалу, онытылу) нәтиҗәсендә, телдә *деэтимологизация* күренеше барлыкка килә. Моңа сәбәпләр булып телдә мотивлаштыручы сүз юкка чыгу, мотивлаштыручы сүз белән мотивлашкан сүз арасында семантик бәйләнешләр өзелү тора. Мәсәлән, *тез* һәм *терсәк* сүзләрен бүген бәйләп карамыйбыз, *төклетура – озын торыклы*; *сердиться – сердце, мешок – мех, столица – стол* һ.б. сүзләрдә дә шундый ук мөнәсәбәтләр күзәтелә.

*Реэтимологизация* – халык этимологиясе (сүзнең яңа эчке форма алуы, мотивлашмаган булудан мотивлашканга әйләнүе; сүзнең мәгънәсен белмәгәндә, кеше аны үзенчә аңларга һәм аңлатырга тырыша). Әмма халык этимологиясе күп очракта фәнни аңлатудан ерак тора, шуңа күрә аны ялган этимология диләр. Ул җанлы сөйләмдә очрый. Сүзләрнең фонетик якынлыгы; мәгънә аңлату максаты белән, сүзнең морфологик элементларын алмаштыру (морфологизация); сүзләрне, тышкы охшашлыгыннан чыгып, семантик якынайту (семасиологизация) нәтиҗәсендә барлыкка килә. Реэтимологизация образлылык, каламбурлык өсти: библиотека – Бибилатыйфа, микроскоп – мелкоскоп, вариация – верояция, пудинг – студинг һ.б.

**Лексикография.** Ике телдә дә сүзлекләр *энциклопедик* һәм *филологик* (лингвистик) дигән ике төркемгә бүленә. Филологик сүзлекләр бер үк вакытта энциклопедик та булырга мөмкин: “Русский язык: Энциклопедия” (Ю.Н.Караулов редакциясендә, 1997).

Лингвистик сүзлекләр бер телле дә, күп телле дә була. Ике яки күп телле сүзлекләр тәрҗемәи характерга ия.

Бер телле лингвистик сүзлекләр берничә төрле була:

1) телнең барлык сүзләрен туплаган сүзлек – тезаурус;

2) хәзерге әдәби тел сүзлеге – аңлатмалы сүзлек;

3) диалекталь / аерым төбәк сүзлеге;

4) аерым язучы теле сүзлеге;

5) аерым бер әсәр теле сүзлеге;

6) тарихи, телнең билгеле бер дәвере сүзлеге;

7) этимологик сүзлек;

8) синонимнар сүзлеге;

9) фразеологик сүзлек;

10) ялгышлыклар (неправильностей) сүзлеге (куллану – әйтү, язуда әдәби тел нормалары иң еш бозыла торган сүзләр сүзлеге);

11) алынмалар сүзлеге;

12) орфографик сүзлек;

13) орфоэпик сүзлек (әдәби тел кысаларында әйтү һәм басым кую);

14) сүз ясалышы сүзлеге;

15) кире (обратный) сүзлек;

16) ешлык сүзлеге;

17) кыскартылмалар сүзлеге;

18) жаргоннар сүзлеге һ.б.

## СҮЗ ЯСАЛЫШЫ

*Морфемаларның төрләре*. Татар телендә: тамыр, кушымча (аффиксаль), нуль морфема. Рус телендә: тамыр (корень, аффиксоид) һәм аффиксаль (префикс / префиксоид, интерфикс, суффикс, окончание, постфикс), нуль морфема.

*Тамыр*. Татар телендә тамыр мөстәкыйль сүз була һәм аерым сүз төркеменә карый.

*Искәрмә*: тамыр һәм аффикс чигендә ике сузык янәшә килә алмау сәбәпле, тамыр морфемадагы соңгы сузык авазның кыскаруы (төшеп калуы): тыңла – тыңл(а)-ый, сөйлә – сөйл(ә)-им һ.б.; әмма диалектта тыңлаем, сөйләем варианты да кулланыла; тамыр морфемадагы соңгы саңгырау тартыкның аңардан соң сузык авазга башланган кушымча килгән очракта яңгыраулашуы, мәсәлән: китап – китабы, колак – колагы һ.б.

Рус телендә тамыр күпчелек очракта мөстәкыйль сүз түгел, лексик берәмлекнең нинди сүз төркеменә каравы кушымчага карап билгеләнә.

*Аффикслар* – өстәмә лексик һәм грамматик мәгънә бирә торган (тамырдан башка) мәгънәле кисәкләр; *яңа сүз ясау, форма ясау* яки *мөнәсәбәт белдерү* (*сүзләрнең башка төрләрен ясау – модаль мәгънә белдерү, сүзләрне төрләндерү (бәйләү))* функцияләрен үтиләр.

Ике телдә дә кушымчалар продуктив (-чы/-че, -лык/-лек, -даш/ -дәш; до-, раз-, при-, -ник, -щик, -ств(о) һ.б., аз продуктив, продуктивлыгын югалткан (фигыльдән исем ясаучы -ак/-әк, -ык/-ек; пра-, су-, -ырь, -оть һ.б.) һәм үле

(-ан/-ән, -ак/-әк, -ры/-ре; -знь, -р-, -тух һ.б.) булырга мөмкин. Үле кушымча тамыр составыннан бүлеп каралмый, аны этимологик анализ ярдәмендә ачыклау мөмкин; продуктив – бүгенге көндә актив рәвештә яңа сүзләр ясала торган кушымчалар; аз продуктив – сирәк кенә яңа сүз ясалырга мөмкин; продуктив булмаган – сүз ясамый, әмма сүз составыннан аерыла.

Татар телендә аффиксларның *суффикс* (тамырдан соң килә торган) төрләре генә бар, алар кушымча дип атала. Бер кушымча бер генә мәгънә белдерә һәм бер мәгънә белдерү өчен бер генә кушымча кулланыла: -лар / -ләр / -нар / -нәр күплек санны белдерә һәм күплек санны әлеге кушымчалар гына белдерә. Фигыльнең зат-сан кушымчасы -быз / -без, тартым кушымчасы -ыбыз / -ебез күплек һәм I зат мәгънәсен белдерә, әмма алар тарихи морфологиядә таркатып карала: -бы-з / -бе-з.

*Искәрмә*: типология белән бәйле карасак, бары суффикслар гына булган телләр префикслар һәм суффикслар булган телләргә караганда күбрәк.

Рус телендә аффиксларның *префикс, интерфикс, суффикс, окончание, постфикс* төрләре бар; типология белән бәйле, алар тамырга карата сүзнең төрле урынында урнаша. Бер кушымча берничә мәгънә белдерә ала: потолок+ø: -ø кушымчасы берлек сан, муж. род, И.п. икәнлекне аңлата; бер үк мәгънәне берничә кушымча белдерергә мөмкин: *Д.п. стол-у / кон-ю, доск-е, матер-и.*

*Сүз ясагыч аффикслар*. Татар телендә *сүз ясагыч кушымчалар* дип атала. Теленең тарихи үсеше барышында һәр сүз төркеменең типик ясагыч кушымчалары барлыкка килгән һәм алар грамматик категория күрсәткечләре кебек, сүз төркемен характерлый, кайбер вакытта бер-берсеннән аеру өчен хезмәт итә.

Рус телендә *сүз ясагыч префикслар, сүз ясагыч суффикслар, сүз ясагыч постфикслар, конфикс (префикс + суффикс), интерфикс, трансфикс (ике нигез кушылганда суффикс + интерфикс)* төрләре өйрәнелә.

*Исем ясалышы*. Татар телендә исем сүз төркеменә караган сүзләр -чы/-че, -лык/-лек, -таш/тәш, -кыч/-кеч, -ма/-мә, -ак/-әк, -ыч/ -еч, -гы/-ге/-кы/-ке һ.б. кшымчалар ярдәмендә ясала. “Татар грамматикасы”нда барлыгы 140лап исем ясагыч кушымча карала, шуларның егерме бере продуктив, арада алынма һәм продуктивлыгын югалтканнары да бар.

Рус телендә исем сүз төркеменә кергән лексик бермлекләр нигездә -тель, -ник, -чик (-щик), -льник, -ие, -тор, -льщик, -ач, -анец, -ость, -изм һ.б. суффикслар ярдәмендә ясала, иң продуктивлар 40тан артык.

*Сыйфат ясалышы*. Татар телендә сыйфатлар -лы/ле, -сыз/-сез, -лык/-лек, -гы/ -ге/-кы/-ке, -чан/-чән һ.б. кушымчалар ярдәмендә ясала. Барлыгы 100гә якын, шуларның 14е продуктив.

Рус телендә сыйфатлар префикс (не-, небез-, пре-, без-(бес-), сверх-, анти-пан- һ.б.), суффикс (-ов-/-ев-, -ат-, -лив-/ -ив- (-чив-), -н-, -ан-(-ян-), -онн- (-

енн-), -ск-(-ческ-, -ическ-, -овск-, -инск-), -ист-, -к-, -оват-(-еват-), -ов-, -ин-), префикс+суффикс: вне-+-н-, -ов-, -ск-; до-, за- + -н-, -ск-, -ов-; на-, над- + -н- һ.б. ярдәмендә ясала.

*Рәвеш ясалышы.* Татар телендә рәвешләр -ча/-чә, -чан/-чән, -лап/-ләп, -лай/-ләй, -лата/-ләтә, -латып/-ләтеп (барлыгы 10лап) кушымчалары ярдәмендә ясала. Рус телендә рәвешләр по- префиксы, -о(-е), -и суффикслары белән ясала.

*Фигыль ясалышы.* Татар телендә фигыльләр 70ләп төр кушымча ярәмендә ясала, шуларның 14е продуктив санала: -ла/-лә, -лан/-лән, -лаш/-ләш, -ылда/-елдә, -а/-ә, -л/-ал/-әл, -ык/-ек, -гар/-гәр/-кар/-кәр, -гыр/-гер/кыр/-кер һ.б.

Рус телендә фигыльләр в-(во-), вы-, за-, из-, от-, под-, над-, при-, у-, на-, с-, пере-, по-, о-(об-) префикслары (фигыльдән фигыль ясала), -а- (-ка-, -ница-, -ича-, -е-, -ова-/-ева-, -и-, -ну- һ.б. суффикслары (исемнән, сыйфаттан фигыль ясала); по- + -ыва- (-ива-); вы- + -ся һ.б. ярдәмендә суффиксаль-префиксаль ысул белән ясала.

*Форма ясагыч яки мөнәсәбәт белдерүче аффикслар.* Татар телендә форма ясагыч аффикслар – грамматик категория күрсәткечләре – бер үк сүз төркеменнән булган барлык сүзләргә ялгана ала; сүз ясагычларны бер үк сүз төркеменең барлык сүзләренә дә ялгап булмый, аерым семантик төркемнәргә генә ялгана ала. Рус телендә форма ясагыч префикс, форма ясагыч суффикс, окончание, сүз төрләндергеч постфикслар бар.

*Нуль морфема* ике телдә дә бар. Бу очракта кушымча булмаган килеш грамматик мәгънә белдерелгәндә була: бала уйный: бала – тамыр морфема, әмма Б.к., берлек санда; ул бара: бара+ø, бара-м, бара-сың формаларына каршы куеп карыйбыз; принёс + ø, принесла, принесли; выход + ø, выхода, выходу, выходе һ.б.

*Нигез.* Ике телдә дә тамыр, ясалма, ясагыч нигез була. Татар телендә кушма, парлы нигез терминнары кулланыла. Рус телендә сүз нигезен һәм сүзформа нигезен аерып карау бар.

## СҮЗДӘ МОРФЕМАЛАР УРНАШУ ТӘРТИБЕ

<table>
<tr><th rowspan="2">татар теле</th><td rowspan="2" colspan="2">---</td><td rowspan="2">тамыр</td><td rowspan="2">---</td><td rowspan="2">тамыр</td><td rowspan="2">сүз ясагыч кушымча</td><td colspan="2">мөнәсәбәт белдерүче кушымча</td></tr>
<tr><td>модаль мәгънә белдерүче</td><td>төрләндергеч (бәйләгеч)</td></tr>
<tr><th>рус теле</th><td>пре-фикс</td><td>пре-фикс</td><td>тамыр</td><td>интер-фикс</td><td>тамыр</td><td>суффикс</td><td>окончание</td><td>постфикс</td></tr>
</table>

## СҮЗ ЯСАЛЫШ ЫСУЛЛАРЫ

***Морфологик*** ысул – телдә кулланылышта булган әзер морфемалар (тат.: тамыр, кушымча / рус.: тамыр, нигез, аффикслар) ярдәмендә, сүз ясалыш типларына таянып, яңа сүзләр ясалу. Рус телендә сүз ясалышы ысуллары *морфема* һәм *мәгънә* белән бәйле ике зур төркемгә бүлеп карала: морфологик, семантик.

Татар телендә *кушымчалау* – сүз ясагыч кушымчалар ялганып, яңа сүзләр ясалу.

*Искәрмә*: Типология белән бәйле рәвештә, татар телендә сүз ясалышы да, форма ясалышы да (сүз төрләнеше) бер типта. Кушма, тезмә, парлы сүзләр ясалу синтаксис белән тыгыз бәйләнештә. Сүз ясагыч кушымчаларга да грамматик категорияләр кебек гомумиләштерү хас: алар да сүз ясалыш рәтен, тибын, калыбын барлыкка китерә. Боларны өйрәнү сүз төркемнәренең үзенчәлекләрен тулырак аңлау, күзаллау мөмкинлеген бирә.

Рус телендә морфологик ысул дигәндә

*а) префикслау* – мөстәкыйль сүзгә приставка өстәлү ярдәмендә яңа сүзләр ясалу;

*б) суффикслау* – сүз ясагыч нигезгә суффикс өстәлеп, яңа сүз ясалу;

*Искәрмә*: Нуль аффикс ярдәмендә (безаффиксальный) сүз ясалу әлеге ысулның бер төре булып каралырга мөмкин; сыйфат белән фигыльдән исем ясау өчен генә кулланыла: *тихий – тишь, бегать – бег;*

*в) конфиксация* – бер үк вакытта ике элемент – префикс + суффикс ярдәмендә сүз ясалу;

*г) постфиксация* – постфикс ярдәмендә сүз ясалу. Гадәттә фигыльгә -ся, -сь, алмашлыкка -то, -либо, -нибудь ялгана.

д-1) *нигез яки сүз кушылу* – мәсәлән, *вагон-ресторан, музей квартира, сердечно-сосудистый, материально-технический һ.б.;*

*Искәрмә*: әлеге тип берәмлекләр

а) аерылмыш-аергыч (определяемое-определяющее) схемасы;

б) ике яки күбрәк санда тулы формалы асыл яки нисби сыйфат арасында тезүле бәйләнеш урнашу ярдәмендә ясала

д-2) рус телендә еш кына *сүз* яки *нигез кушылу ысулы интерфикслау белән бергә бара: газ+о+провод=газопровод;*

д-3) нигез кушылу ысулының *аббревиация* төре күздә тотыла: *профсоюзный комитет – профком (иҗекләр ярдәмендә), научно-исследовательский институт – НИИ* (аваз ярдәмендә), *Камский автомобильный завод – КамАЗ* (катнаш төрле).

Морфологик сүз ясалышы ике телдә дә кулланыла, әмма үзенчәлекләр бар: татар телендә морфологик ысул дигәндә *кушымчалау* ысулы гына каралса, рус телендә *аффиксаль* (префикс, суффикс, конфикс, постфикс

ярдәмендә) ысулдан тыш, татар телендә *синтаксик* ысул буларак карала торган *нигез кушылу, аббревиация* ысуллары да карала.

***Синтаксик*** ысул – сүзләрнең структур һәм семантик бәйләнешкә керүе нәтиҗәсендә яңа сүзләр ясалу. Татар телендә әлеге ысул белән *кушма, тезмә, парлы* сүзләр ясала (копулятив);

*Искәрмә*: кушма һәм тезмә сүзләрне аеру принциплары: 1) компонентларда төрле фонетик үзгәрешләр барлыкка килү: бу+көн=бүген; 2) төрле грамматик үзгәрешләр барлыкка килү: кузы+колагы=кузгалак; 3) просодик үзенчәлек буларак кушма сүзнең бер басымлы булуы; 4) кушма сүз компонентлары комплетив, предикатив, I төр изафә мөнәсәбәтләренә ия була [Хисамова, 2006: 39-40].

Рус телендә әлеге ысулга семантик ысулның *сүзтезмә лексикалашу* төре туры килә (еш кына сыйфат + исем); мәсәлән, тяжело + раненный – тяжелораненный. Бу очракта исем төшеп калып, сыйфатка суффикс өстәлү дә күзәтелә: *с ума сшедший — сумасшедший, за благо рассудится — заблагорассудится, сего дня — сегодня.* Хәзерге рус телендә бу ысул белән сыйфатлар гына ясала: *быстро растворимый — быстрорастворимый* (кофе), *вечно зеленый — вечнозеленый* һ.б. Шул сәбәпле кайбер дәреслекләрдә бу ысулны лексик-синтаксик дип карау да очрый [Валгина и др. 2003: 137].

*Искәрмә*: Парлы сүзләр һинд-европа телләрендә сирәк күренеш. Ул төрки телләр спецификасы булып тора. Нигез яки сүз кушылып сирәк кенә ясала торган сүзләр морфологик ысул буларак өйрәнелә.

***Аббревиация*** ысулы – төрле телләргә хас булган типологик уртаклыклар нигезендә сүзтезмә яки тезмә сүзләрнең кыскаруы нәтиҗәсендә яңа сүз ясалу. Татар телендә синтаксик ысулның бер төре, рус телендә морфологик ысулның бер төре *нигез кушылу ысулы* буларак карала.

***Конверсия*** яки морфологик-синтаксик ысул – бер сүз төркеменнән икенчесенә күчү. Татар телендә конверсия күренеше системалы рәвештә сыйфат фигыль һәм исем фигыльнең, сыйфатның исемгә; сыйфат фигыльнең сыйфатка күчүендә күренә.

*Искәрмә*: Исемне фигыльдән аеру өчен юклык формасына яки фигыльгә хас башка грамматик категорияләргә куеп карау кирәк.

Туң (мерзлый), туң (мерзлота), туң-у (мерзнуть) һ.б. кебек бер үк вакытта исем, сыйфат һәм фигыль мәгънәсен белдергән сүзләр борынгы төрки телдәге синкретизм күренеше булып санала.

Рәвеш, алмашлык, ярдәмлек сүзләр арасында да әлеге ысул белән ясалган берәмлекләр бар. Әмма алар арасында билгеле бер эзлеклелек юк – алар төрле сүз төркемнәренең изоляцияләнүеннән барлыкка килгән, шулай да рәвешләр арасында хәл фигыльдән ясалганнары ешрак очрый [Хисамова, 2006: 48].

Рус телендә конверсия – семантик ысулның бер төре – *грамматик форманың лексикалашуы* – сүзнең яңа мәгънә һәм грамматик билгеләр алуы аша башка сүз төркеменә күчүе: *утром (исем, берлек сан, тв.пад.) – утром (рәвеш), заведующий (сыйфат) – заведующий (исем).*

*Искәрмә*: Валгина һ.б. хезмәтендә морфологик-синтаксик ысул дип атала [Валгина и др., 2003: 137].

Синкретизм күренеше рус теле материалында да сакланган дип карала. Мона мисал: бер үк кушымчада берничә грамматик категория белдерелү стран-а – жен.род, им.п., ед.числ.

***Лексик-семантик*** ысул – сүзләрнең күчерелмә мәгънәләренә нигезләнеп яңа сүзләр ясалу: *койрык – хайван койрыгы, самолет койрыгы, тапшырылмаган имтихан*. Ике телдә дә бер үк характерга ия. Рус телендә семантик ысулның *мәгънә лексикалашу* төре – телдә булган сүзнең мәгънәсе киңәеп, яңа мәгънәдә кулланыла башлавы буларак өйрәнелә: *звезда – күктәге йолдыз, сәхнә йолдызы, кулак – йодрык, кулак (сословие).*

*Искәрмә*: Н.С.Валгина, Д.Э.Розенталь, М.И.Фомина хезмәтендә бу ысул лексик-семантик дип атала [Валгина и др, 2003: 136].

*Фонетик* ысул (аваз төшеп калу, өстәлү; басым үзгәрү; аваз чиратлашу; нигез палатальләшү): хәрәм – әрәм; ә'ле-әле', я'ңа-яңа'; сач – чәч; сылтау – селтәү һ.б. Рус телендә сүз ясалу ысулы буларак каралмый.

**Сүз ясалыш мәгънәсе.** Сүз ясагыч нигез һәм яңа ясалган сүз арасында структур яктан гына түгел, мәгънә ягыннан да бәйләнеш була. Сүз ясалыш мәгънәсе, лексик мәгънәдән аермалы буларак, аерым сүзнең индивидуаль мәгънәсе түгел; грамматик мәгънәдән аермалы буларак, аерым сүз төркеменә караган берәмлекләрнең кайберләренә генә хас. Ягъни, ясалма сүзләрдә махсус чара – сүз ясагыч берәмлек ярдәмендә белдерелә торган мәгънә. Мәсәлән, *учить – учитель, укыту – укытучы, читать – читатель, уку – укучы*: ясалма сүз ясагыч нигез белдергән эшне үтәүче затны аңлата.

Татар телендә ясалма сүз составындагы нигез шул ук мәгънәдә телдә аерым кулланыла алырга тиеш.

**Сүз ясалыш тибы.** Бер үк сүз төркеменнән бер үк кушымча белән ясалган, бер үк сүз ясалыш мәгънәсенә ия булган сүзләр бер сүз ясалыш тибына карыйлар. Әмма мәгънәләр гомуми һәм хосусый була, ягъни төрле мәгънә төсмерлә белдерелә: *урак-чы, баян-чы* (билгеле бер корал белән эшләүче), *кибет-че, юл-чы* (эш урынын), *таш-чы, печән-че* (эш объектын) һ.б.

Сүз ясалыш тибын билгеләгәндә сүз ясалыш ысулы, ясалма һәм ясагыч сүзнең лексик-грамматик үзенчәлекләре, сүз ясагыч чара, ясагыч һәм ясалма сүзнең семантик бәйлелеге һәм аларның сүз ясалыш мәгънәсе истә тотылырга

тиеш. Сүз ясалыш тибы – ул сүзнең *структур-семантик схемасы*. Продуктив һәм продуктивлыгын югалткан типлар була.

Тәрҗемә иткән вакытта сүз ясалыш типлары туры килергә дә, килмәскә дә мөмкин: *кызыллык, сарылык, кирелек, ялкаулык = краснота, желтизна, упрямство, ленивость (сыйфат+-лык); чукраклык, телсезлек, сукырлык = глухота, немота, слепота (сыйфат+-лык)*. Беренче төркем мисаллар белән икенчеләре бер үк төрле ясалган булса да, тәрҗемәдә беренчеләре – төрле, икенчеләре – эквивалент.

**Сүз ясалыш моделе.** Телдә сүзләр борынгыдан ук формалашкан әзер калып-модельләр нигезендә ясала. Сүз ясалыш моделе – *сүз ясалу схемасы* ул. Продуктив һәм продуктивлыгын югалткан модельләр була: юл-даш, әңгәмә-дәш; ур-ак, сана-к. Сүз ясалыш моделе ясалма сүзнең ясалыш ысулы, нинди сүз төркеменә каравы, ясагыч сүзнең лексик-грамматик характеристикасына, конкрет сүз ясагыч формантага бәйле. Татар телендә бер модельле ясалышка мисаллар: *балтачы, тимерче* – исем+-чы; *сукырлык, нечкәлек* – сыйфат+-лык; *йоклап алу, тотып алу* – фигыль+ алу ярдәмче фигыле һ.б.

Хәзерге рус телендә ясагыч сүзнең лексик-грамматик характе-ристикасы, сүз ясагыч формантасы бердәй булган ясалма сүзләр бер үк сүз төркемнә караганга күрә, сүз ясалыш моделен билгеләү җиңелрәк.

Бер модельле ясалышка мисал итеп, *машинист, гитарист* (исем + -ист); *резвиться, упрямиться* (сыйфат+-и-+-ся) кебек сүзләрне китерергә мөмкин.

Төрле модельле ясалыш: *пригородный, подмосковный* – префикслар төрле; *железнодорожный, девятиэтажный* – беренче компонент төрле сүз төркеменә карый.

Татар һәм рус телләрендә сүз ясалыш модельләрен чагыштыру ясалма сүзләрнең структур-семантик үзенчәлекләре барлыгын күрсәтә. Мәсәлән, татар яки рус телендә бер үк модель белән ясалган сүзләрне тәрҗемә итсәк, алар төрле модельле булачак: *кайгысыз, башсыз* (исем+-сыз) = *беззаботный, глупый* (без-+забот+-н-+ый, тамыр сүз).

**Сүз ясалыш оясы** – бер үк ясагыч нигездән төрле кушымчалар белән сүзләр ясалу. Агглютинатив характерлы татар телендә тамыр мөстәкыйль булганга, сүз ясалыш оялары бик киң таралмаган

Рус телендә сүз ясалыш оялары бик актив. Оядагы сүзләрнең бер-берсенә буйсынуы тәртип белән бара һәм сүз ясалыш оясы сүз ясалыш парларыннан тора. А.Н.Тихонов сүзлеге рус теленең сүзлек байлыгы сүз ясалышы ояларыннан торуын раслый: макрооялар 400-500гә кадәр берәмлекне үз эченә ала.

**Сүз ясалыш чылбыры** – бер үк тамырга бер-бер артлы берничә кушымча ялганып сүз ясалу. Бу очракта сүз ясагыч нигез һәр берәмлек өчен

яңа була. Соңгысыннан башка лексик берәмлекләр барысы да ясагыч була. Ике телдә дә күпчелек сүз төркемнәре чылбыр башында килә ала. Әмма тәрҗемә иткәндә, алар һәрвакыт туры килми. Татар телендә, гадәттә, иң күбе 4ләп пар очрый. Рус телендә сүз ясалыш чылбыры 7гә кадәр пардан торырга мөмкин.

## МОРФОЛОГИЯ

Телдәге һәрбер сүз, барлык телләр өчен дә уртак булган принципларга нигезләнеп, билгеле бер сүз төркеменә карый. Сүз төркемнәренә бәйле татар теленә түбәндәге үзенчәлекләр хас: хәбәрлек сүзләр бар; аваз ияртемнәре – мөстәкыйль сүз төркеме; исем һәм фигыль генә төрләнүче сүз төркемнәре; татар телендә, ясалма берәмлекләрдән кала, сүзнең кайсы сүз төркеменә керүен белдерә торган формаль күрсәткеч юк. Рус телендә: категория состояния бар; аваз ияртемнәре мөстәкыйль сүз төркеме түгел; исем һәм фигыльдән тыш сыйфат, сан, алмашлык та төрләнә; ясагыч аффикслар ярдәмендә генә түгел, окончаниеләр ярдәмендә дә сүзнең кайсы сүз төркеменә керүен ачыклап була.

**Исем** – имя сүществительное. Ике телдә дә предметлыкны, затны, халәт һәм хәрәкәт исемен белдерә; мәгънә ягыннан төркемнәре: ялгызлык / уртаклык; конкрет / абстракт, предметлык / матдәлек, җыйма (собирательные). Уртак билгеләре – килеш белән төрләнү, сан категориясе хас булу.

Татар телендә исемнәр барысы да бер типта төрләнә, тартымлы һәм тартымсыз төрләнеш кенә аерып карала. Килеш белдерү чарасы – килеш кушымчалары.

Рус телендә килеш белән төрләнешнең берничә тибы бар: I, II, III төр төрләнеш, төрле төрләнешкә ия һәм төрләнми торган исемнәр бүлеп карала; килешне белдерү чаралары: флексия, басым үзгәрү, чиратлашу, аналитик, сүз тәртибе.

Ике телдә дә берлек һәм күплек сан формалары кулланыла. Татар телендә күплек сан -лар/-ләр/-нар/-нәр кушымчалары ярдәмендә белдерелә. Рус телендә күплек сан кушымчалар (ромашка – ромашки), форма ясагыч суффикслар (*звено – звень-ја, дочь – доч-ери)*, супплетивизм күренеше (*ребенок – дети, человек – люди*), басым үзгәрү (*озеро – озер**а**, лес – лес**а***) ярдәмендә белдерелә.

Рус теленең тагын бер үзенчәлеге – күплек яки берлек санда гына кулланыла торган исемнәр булу.

Уникаль категорияләр. Татар телендә исем сүз төркеменә

– *тартым* категориясе хас. Ул синтетик, аналитик, аналитик-синтетик юллар белән белдерелә. Рус телендә бу категория юк, әмма тартым мәгънәсен белдерү өчен затка мөнәсәбәтле сүзләр файдаланыла;

– *хәбәрлек* категориясе – исемнең җөмләдә хәбәр булып килүен белдерә;

– функциональ-семантик планда исемгә *билгелелек / билгесезлекне* белдерә алу хас.

Рус телендә исем сүз төркеменә кергән лексик берәмлекләр

– *род* категориясенә нигезләнеп, 5 төркемгә бүленә: исемнәр өч грамматик җенеснең (*родның*) берсенә карый, гомуми (общий) родлы яки роды билгеләнми торган сүзләргә бүленә. Исем белән килгән сыйфат, сыйфат фигыль, алмашлык, тәртип саны *род, сан, килештә* яраша. Татар телендә род категориясе юк, мәгънә аерым лексик берәмлекләр белән белдерелә ала: үгез / сыер, ата каз / ана каз, ир бала / кыз бала. Рус телендә дә мондый очраклар бар.

– *җанлы* (одушевленный) *яки җансыз*га (неодушевленный) бүленә. Татар телендә бу категориянең эчтәлеге кеше турында кем? калган очракларда нәрсә? соравы куелу белән чикләнә, мөстәкыйль категория түгел.

Синтаксик яктан исемнәр ике телдә дә беренче чиратта ия, тәмамлык булып килә, җөмләнең теләсә кайсы кисәге функциясен башкарырга мөмкин.

**Сыйфат** – имя прилагательное – предметның һәм затның билгесен белдерә. Ике телдә дә асыл һәм нисби сыйфатлар бар. Рус телендә моннан тыш тартым сыйфатлары кулланыла. Татар телендә -ныкы / -неке кушымчалы сүзләрне тартым сыйфатлары дип карау уңышлы саналмый.

*Искәрмә*: татар телендә нисби сыйфатлар һәрчак ясалма була.

Татар телендә сыйфатлар төрләнми. Төп, чагыштыру (-рак/-рәк, аерым сүз ярдәмендә), артыклык (иң, чем, дөм, үтә һ.б. кисәкчәләр), кимлек (-елҗем, -сыл, -су, -кылт, -кылтым) дәрәҗәләре хас.

Рус телендә – килеш, сан, род белән төрләнә; әлеге категорияләр исем белән ярашу күрсәткечләре буларак карала. Төрләнеш өч типта була:

1) *-ый, -ий, -ой (желтый, летний, золотой)*;

2) *-ин, -ов / -ев (дядин, отцов)*;

3) *-иj* (лисий);

Дәрәҗәләр: төп, чагыштыру (-ее(-ей), -е, более, менее), артыклык (-ейш-, -айш-, самый, наиболее, наименее + төп дәрәҗә, всех, всего + чагыштыру дәрәҗәсе).

Синтаксик яктан татар телендә күбрәк очракта исем белән белдерелгән җөмлә кисәген ачыклап, аергыч ролендә кулланыла, хәбәр, хәл булырга мөмкин (нисби сыйфатлар нигездә аергыч була). Рус телендә дә күпчелек очракта аергыч булып килә, исем хәбәр составында да кулланылырга мөмкин.

Рус телендә сыйфатның тулы һәм кыска вариантлары була.

*Искәрмә*: Әмма барлык асыл сыйфатларның да кыска варианты юк (төс, субъектив бәяләү һәм -ск-, -ов-/-ев-, -н-, -л- суффикслы); бары кыска формада гына кулланыла торган сыйфатлар бар: должен, готов; кыска һәм тулы вариантларда мәгънә, стиль төрлелеге мөмкин: видный ученый – город виден, больной человек – человек болен; кыска вариант төрләнми, тезмә исем хәбәр составында кулланыла.

**Сан** – имя числительное – предметның санын, исәбен белдерә. Төзелеше ягыннан саннар гади, кушма, тезмә була.

Ике тел өчен дә уртак булган сан төркемчәләре: микъдар, тәртип (-нчы/-нче // (сыйфатлар ясалышы кебек) -ый/-ая/-ое), җыю (-ау/-әү // -j(е)/ -ер(о). Вакланмалы саннар татар телендә микъдар саны буларак карала, рус телендә аерым төркемчә булып тора.

*Искәрмә*: Рус телендә тәртип саны югары уку йорты дәреслекләрендә түбәндәге билгеләр нигезендә нисби сыйфатка якын дип карала:

1) предметның тәртип буенча билгесен белдерә, микъдар саны – исәбен;

2) род, сан, килеш белән төрләнә, ә микъдар саннары килеш белән генә;

3) сыйфатныкы кебек кушымчалар ала, ә микъдар саннары хәзерге рус телендә үзенчәлекле (12 типта) төрләнешкә ия;

4) тезмә тәртип санының соңгы берәмлеге генә төрләнә, микъдар санында барысы да;

5) исем белән тәртип саны тезмәсе синтаксик тотрыклы түгел, ә микъдар саны белән исем таркалмый торган сүзтезмә буларак карала;

6) тәртип санында “сыйфатлык” билгесе буларак *-ый, -ая, -ое, -ja, -ов-, -н-* аффиклары кулланыла.

Татар теленә генә хас булган сан төркемчәләре: бүлем (-ар/-әр, -шар/-шәр), чама (-лап/-ләп, якын саннарны кабатлау) саннары. Бүлем, чама саннары рус телендә по-, около кебек ярдәмче берәмлекләр белән, аерым очракларда сүз тәртибе һ.б. белән белдерелә.

Рус телендә бу сүз төркеменә сан ягыннан билгесезлекне белдерә торган сүзләр дә кертеп карала.

*Искәрмә*: Әлеге берәмлекләр (неопределенно-количественные слова) мәктәп дәреслекләрендә рәвеш, алмашлык составында карала.

Морфологик яктан татар телендә саннар төрләнми.

*Искәрмә*: Абстракт саннарны белдергәндә һәм исемләшкәндә килеш, тартым, сан категорияләре хас.

Рус телендә сан саналмыш белән ярашып килә, төрләнә, әмма һәр лексик берәмлек түгел. *Один, два, оба, полтора* берәмлекләренә род, *два, оба, три,*

*четыре* берәмлекләренә җанлылык / җансызлык, *один*га – сан (сыйфатка охшаш) хас; килеш иң тулы чагылыш тапкан категория (кушымчаларда бертөрлелеккә омтылыш күзәтелә).

Синтаксик яктан татар телендә исем белән белдерелгән кисәкне ачыклап, аергыч функциясендә килә; сирәгрәк, фигыльне ачыклап, хәл була ала; бу очракта нумератив сүзләр куллану күзәтелә.

Рус телендә исем белән генә кулланыла, синтаксик яктан мондый сүзтезмәләр таркатылмыйча, бер җөмлә кисәге итеп карала. Сыйфат белән кулланылмый.

**Алмашлык** – местоимение – ике телдә дә чынбарлык күренешләрен турыдан-туры атамыйча, гомуми рәвештә аларга ишарәли һәм сөйләмдә башка сүз төркемнәрен алыштырып килә торган сүз төркеме.

Ике тел өчен дә уртак булган сан төркемчәләре: зат, күрсәтү, сорау, билгеләү, билгесезлек, юклык, тартым (нисбәтләү). Болардан тыш рус телендә кайтым (возвратное) алмашлыгы кулланыла.

Морфологик яктан татар телендә үзе алыштырып килгән исем, сыйфат, сан, рәвеш сүз төркемнәренең грамматик билгеләрен ала.

*Искәрмә*: зат алмашлыклары тартым белән төрләнми.

Рус телендә алмашлыкларның род, килеш, сан белән төрләнүдә бердәм булмавы әлеге төркемгә кергән лексик берәмлекләрнең семантик, грамматик яктан төрлечә характерлануы белән аңлатыла.

Грамматик билгеләренә карап, ике телдә дә алмашлыклар өч төркемгә бүленә:

1) исем алмашлыклар;

2) сыйфат алмашлыклар;

3) сан алмашлыклар;

татар телендә 4) рәвеш алмашлыклары да бар.

Синтаксик яктан алмашлаклыр үзе алыштырган сүзләр вазыйфасын башкара һәм төрле җөмлә кисәге булып килә ала.

**Рәвеш** – наречие – эш-хәл яки билгенең билгесен белдерә торган сүз төркеме.

Татар телендә рәвешләрнең төркемчәләре:

1. Билге рәвешләре:

1) эшнең үтәлү рәвеше яки башка билгесе буенча характерлый (тиз-тиз, бушлай);

2) эш-хәлне күләм-чама ягыннан ачыклый (озак, күп, һаман);

3) эш-хәлнең үтәлү дәрәҗәсен яки билге дәрәҗәсен белдерә торган (тәмам, бик, җиңелчә);

4) эш-хәлне, процессны чагыштыру аша ачыклый торган рәвешләр (безнеңчә, уттай);

2. Хәл рәвешләре:

1) вакыт (һәрчак, башта, җәен);

2) урын (еракта, бире, якын);

3) сәбәп-максат (юкка, юри, тиктомалга, заяга).

Рус телендә рәвешләрнең төркемчәләре:

1. Билге рәвешләре:

1) *-о, -э* суффикслары ярдәмендә сыйфаттан ясалган асыл (качественные) рәвешләр, (дәрәҗә хас: *весело, хорошо, прекрасно)*;

2) микъдар (количественные) рәвешләре: *дважды, втроем, вдвойне, втрое*;

3) сыйфатлау рәвешләре (образа или способа действия) фигыль белән генә кулланыла: *вслух, тайком, столбом*;

4) күләм-чама (меры и степени) рәвешләре: *очень, весьма, абсолютно, чрезвычайно, крайне, совсем, совершенно, слишком, еще*;

5) бергәлек рәвешләре (наречия со значением совместности действия): *стаями, поротно, парами, толпами*;

6) охшату-чагыштыру рәвешләре (сравнительно-уподобительные) *по...ски / ески, по...ому / ему, по...j* ярдәмендә ясала: *по-дружески, по-доброму, по-волчьи.*

2. Хәл рәвешләре:

1) вакыт рәвешләре: *вчера, днем*;

2) сәбәп рәвешләре: *поневоле, созла*;

3) максат рәвешләре: *нарочно, назло*;

4) урын рәвешләре *слева, вперед*;

3. Алмашлык рәвешләре, ясалышы ягыннан алмашлык белән бәйле: *по-моему, куда, когда* һ.б.

Морфологик яктан рәвешләр ике телдә дә төрләнми, кайбер рәвешләргә генә дәрәҗә формалары хас.

Синтаксик яктан чагыштырыла тоган телләрдә рәвешләр күбрәк фигыль, сыйфат, башка бер рәвешне ачыклап, хәл функциясен башкара: *озак утыру; идти медленно.* Исемне ачыклап, аергыч та булырга мөмкин: *күп еллар, татарча китап, кофе по-турецки* һ.б.

**Фигыль** – глагол – эш яки хәлнең үтәлү процессын белдерә.

Морфологик яктан ике телдә дә фигыльләргә зат-сан, заман, төркемчә категорияләре хас. Моннан тыш, татар телендә юнәлеш, барлык/юклык, дәрәҗә; рус телендә вид, род категорияләре кулланыла.

Татар һәм рус фигыльләре өчен хас булган *уртак грамматик категорияләр*:

– төркемчә – наклонение: хикәяләү (изъявительное), боеру (повелительное), шарт (сослагательное). Татар теленә теләк, шартлы теләк төркемчәләре дә хас;

– юнәлеш – залог: төп (действительный), төшем (страдательный), кайтым (возвратный). Татар телендә уртаклык, йөкләтү юнәлешләре кулланыла;

– заман – время: үткән, хәзерге, киләчәк заманнарны белдерү өчен татар телендә тугыз:

1) билгеле (категорик) үткән заман: -ды/-де, -ты/-те;

2) билгесез (нәтиҗәле) үткән заман: -ган/-гән, -кан/-кән;

3) тәмамланмаган үткән заман: -а иде;

4) тәмамланган (күптән үткән) үткән заман: -ган иде;

5) кабатлаулы үткән заман: -а торган иде;

6) хәзерге заман: -а/-ә, -ый/-и;

7) билгеле киләчәк заман: -ачак;

8) билгесез киләчәк заман: -ыр;

9) киләчәк үткән заман: - ачак иде;

рус телендә биш:

1) совершенный вид үткән заман;

2) несовершенный вид үткән заман;

3) хәзерге заман;

4) совершенный вид киләчәк заман;

5) несовершенный вид киләчәк заман (аналитик форма) фигыль формасы кулланыла.

– зат-сан категориясе татар телендә калын/нечкә, тулы/кыска варианттагы кушымчалар белән белдерелә; рус телендә зат һәм сан белән төрләнеш үзенчәлекләренә бәйле фигыльләр түбәндәге төркемнәргә бүленә:

- I төрләнеш / I спряжение;

- II төрләнеш / II спряжение (II төрләнешкә: -ить формалы *(брить, стелить*тән тыш), -еть формалы 7 фигыль (смотреть, видеть, ненавидеть, обидеть, терпеть, зависеть, вертеть), -ать формалы 4 фигыль (гнать, держать, слышать, дышать) карый.

- төрле төрләнешле (бежать, хотеть, чтить);

- архаик төрләнешле (дать, есть, создать, быть);

- артык төрләнешле / избыточные (лазить, мучить һ.б.);

- ким төрләнешле / недостаточные (победить, убедить, очутиться, близиться, басить һ.б.);

- төрләнми торган / безличные (светает, вечереет һ.б.)

Калган фигыльләр I төрләнеш.

*Уникаль грамматик категорияләр*дән татар теленә барлык/юклык, дәрәҗә хас.

Барлык/юклык – татар телендә барлык фигыльләргә дә хас; бары кайбер хәл фигыль һәм эшнең үтәлү дәрәҗәсен, рәвешен белдерә торган аналитик фигыль формалары белән кулланылмый. Күрсәткече – -ма/-мә кушымчасы – бары фигыльгә генә ялгана. Калган сүз төркемнәре һәм кайбер затланышсыз фигыль формалары *түгел* кисәкчәсе белән кулланыла.

*Искәрмә*: рус телендә юклык аспекты барлык сүз төркемнәре өчен дә хас булган универсаль *не* кисәкчәсе ярдәмендә белдерелә

Дәрәҗә – эшнең үтәлү-үтәлмәү дәрәҗәсен белдерә. Түбәндәге мәгънә төсмерләре бар: башлану, юнәлү, кабатлану, кинәтлек, дәвамлылык, өлешчә үтәлү, тәмамлану. Синтетик һәм аналитик чаралар ярдәмендә белдерелә.

*Искәрмә*: рус телендә дәрәҗә категориясенә өлешчә төр (вид) категориясе һәм фигыльле хәрәкәт ысуллары (способы глагольного действия) туры килә.

Рус телендә фигыльләргә хас булган уникаль грамматик категорияләргә вид һәм грамматик җенес (род) карый.

Төр (вид) – процессның төгәлләнгән / чикле (СВ), төгәлләнмәгән / чикләнмәгәнлеген (НСВ) белдерә. Күпчелек фигыльләр ике төрдә дә кулланыла; бер генә төрдә кулланыла: *хлынуть, очнуться, рвануть* (СВ); *сидеть, ходить, лететь* (НСВ); төре контекстта гына ачыклана торганнары да бар: *жениться, исследовать* һ.б. Төр күрсәткечләре: префикс, суффикс, басым, супплетивизм, аваз чиратлашу.

Род категориясе рус фигыленең грамматик төзелешен характерлый торган күренеш булып саналмый. Фигыльләрнең берлек сандагы кайбер формалары (үткән заман, шарт фигыль, сыйфат фигыль) гына өч родның берсендә кулланыла.

Ике телдә дә фигыльләр затланышлы һәм затланышсыз була.

Татар һәм рус телләре өчен уртак булган затланышсызлы фигыльләр: сыйфат фигыль (причастие), хәл фигыль (деепричастие), инфинитив (неопределенная форма/инфинитив). Татар телендә болардан тыш исем фигыль формасы кулланыла.

*Искәрмә*: ике телдә дә фигыльләргә төркемчә категориясе хас булу; хикәя фигыльләрнең заман, хикәя һәм боерык фигыльләрнең (өлешчә), татар телендә шарт фигыльнең дә зат-сан; рус телендәге аерым фигыль формаларының грамматик җенес (род) белән төрләнүе

затланышлы/спрягаемые фигыль формаларын барлыкка китерә. Затланышлы һәм затланышсыз фигыль формаларын берләштерә торган билгеләр: лексик мәгънә уртаклыгы; татар телендә барлык/юклык, юнәлеш, дәрәҗә, рус телендә төр (вид), төркемчә (залог) категорияләрен алу; башкарылу (управление) хас булу; рәвеш белән бәйләнешкә керә алу мөмкинлеге. Затланышлы фигыльләрнең синтаксик функциясе хәбәр булу (затланышлы фигыльләрне рус тел белемендә предикативные формы дип атыйлар), затланышсыз формалар җөмләнең иярчен кисәкләр (сыйфат фигыль – сыйфат, хәл фигыль – хәл) ролен дә башкара алалар (рус тел белемендә атрибутивные дип аталалар).

*Сыйфат фигыль – причастие* – предметның билгесен эш аша белдерә. Исемләшә. Юнәлеш категориясе хас. Үзе иярткән исемнең билгеле бер килештә торуын таләп итә. Җөмләдә аергыч функциясен башкара.

Татар телендә үткән заман (-ган), хәзерге гади (-учы), хәзерге тезмә (-ый торган), киләчәк (-ыр, -асы, -ачак) заман формалары кулланыла. Барлык-юклык категориясе хас.

Рус телендә үткән һәм хәзерге заман формалары бар. Төр (вид), килеш, грамматик җенес (род), сан категорияләре хас.

Татар һәм рус телендә фигыльләрнең типик синтаксик функциясе – хәбәр булып килү.

*Искәрмә*: типологик үзенчәлеге буларак, татар телендә фигыль формалары еш кына исемләшә.

*Хәл фигыль – деепричастие* – ике телдә дә төп фигыльдән аңлашылган эш-хәлгә өстәмә эшне белдерә һәм аны ачыклый. Юнәлеш категориясе хас. Үзе ияргән исемнең билгеле бер килештә торуын таләп итә. Җөмләдә хәл функциясен башкара, иярчен җөмлә хәбәре буларак, яки баш җөмлә хәбәре составында килә ала. Болардан тыш, татар телендә хәл фигыльгә барлык-юклык хас. Дүрт төр (-ып, -ый, -гач, -ганчы) хәл фигыль формасы бар. Рус телендә хәл фигыльләр төр (вид) категориясен ала.

*Инфинитив – неопределенная форма глагола* – эш-хәлне атау белән чикләнә һәм төрләнми торган фигыль төркемчәсе. Юнәлеш категориясе хас. Җөмләдә тәмамлык, хәл булырга, хәбәр составында килергә мөмкин. Татар телендә барлык/юклык, дәрәҗә формалары; рус телендә төр (вид) кулланыла.

*Исем фигыль* – исем һәм фигыль билгеләрен үзендә туплаган фигыль формасы. Килеш, тартым, сан; барлык / юклык, юнәлеш, дәрәҗә категорияләре хас, үзе ияртеп килгән исемнең билгеле бер килештә килүен таләп итә. Җөмләдә ия, хәбәр, аергыч, тәмамлык, хәл, аныклагыч

функцияләрен үти ала. Әлеге фигыль формалары рус теленә инфинитив, отглагольное существительное булып тәрҗемә ителергә мөмкин.

*Фигыль нигезе*. Татар телендә II зат берлек сан боерык фигыль формасы белән тәңгәл килә; тамыр, ясалма, кушма, тезмә булырга мөмкин.

Рус телендә фигыль нигезе хәзерге заман (III зат күплек сан формасыннан карала: *ход-ят, бросаj-ут*) һәм инфинитив (инфинитив кушымчасы алынып табыла: *бежа-ть*) нигезе була. Ике нигез туры килергә мөмкин: *нес-ти, нес-ут*. Беренчесеннән боерык фигыль, хәзерге заман сыйфат фигыль һәм несовершенный вид хәл фигыль ясала; инфинитив нигезеннән үткән заман формалары, шарт фигыль, үткән заман сыйфат фигыль һәм совершенный вид хәл фигыльләр ясала.

**Аваз ияртемнәре** – звукоподражательные слова – һәр телнең үз үзенчәлекләре нигезендә кеше, хайван, җансыз предметлар тудыра торган авазларга охшатып ясалган сүзләрне туплаган сүз төркеме. Татар телендә мөстәкыйль сүз төркеме буларак өйрәнелә, рус телендә ымлыклар белән бергә карала. Татар телендә табигать күренешләрен образлы итеп күз алдына китерү өчен кулланылган ияртемнәр дә шунда ук карала.

Татар телендә аваз ияртемнәренең төркемчәләре:

Аваз ияртемнәре:

1. Хайван, җәнлек, кош-корт, бөҗәк тавышларын тасвирлый торган аваз ияртемнәре.
2. Җансыз предметлар чыгара торган тавышларга охшатып ясалган аваз ияртемнәре.
3. Кеше хәрәкәте тудырган тавышка охшатып ясалган аваз ияртемнәре.
4. Кеше тавышына охшатып ясалган аваз ияртемнәре.

Образ ияртемнәре:

1. Яктылык һәм төс тасвирлары.
2. Хәрәкәт тасвирлары.
3. Эчке сиземләү, психик халәт тасвирлары.

Рус телендә төркемчәләре:

1. Кош-корт, хайван тавышларын;
2. Табигать тавышларын;
3. Кеше эшчәнлеге белән бәйле тавышларны тасвирлый торган аваз ияртемнәре

Морфологик яктан аваз ияртемнәре төрләнми, әмма алар нигезендә яңа сүзләр ясала: *шакылдау, кытаклау, кукарекать, хихикать һ.б.*

Синтаксик яктан татар телендә җөмләдә рәвеш хәле, сирәк кенә ия, хәбәр булырга мөмкин.

*Искәрмә*: Чынбарлык күренешләрен атап күрсәтмичә, кыска юл белән белдерәләр, номинатив функцияләре юк, әмма морфологик һәм синтаксик яктан мөстәкыйль сүз төркемнәре белән охшаш булганга, мөстәкыйль сүз төркеме итеп карала.

Рус телендә туры сөйләм буларак кулланыла ала; хәбәр булырга мөмкин.

**Хәбәрлек сүзләр** – категория состояния (безлично-предикативные слова). Татар тел белемендә чынбарлыктагы предмет, күренеш һәм төшенчәләргә мөнәсәбәт белдерүе белән модаль сүзләргә, лексик эчтәлеге һәм морфологик формалары булу белән мөстәкыйль сүз төркемнәренә якын дип тасвирлана. Рус тел белемендә гомумкатегориаль яктан җан ияләре, табигать, әйләнә тирәлек халәтен белдерүче сүз төркеме буларак характерлана.

Татар телендә төркемчәләргә бүленми, рус телендә:

1) асыл (качественные) предикатив сүзләр

- кешенең эмоциональ-психик халәтен белдерә: *грустно, весело*;

- кешенең физик яки физиологик халәтен белдерә: *голодно, больно*;

- табигать, әйләнә-тирәлекнең физик, метеорологик халәтен белдерә: *уютно, пасмурно* һ.б.

2) модаль предикатив сүзләр: *надо, нужно, лень, необходимо, довольно, хватит* һ.б.

Татар телендә хәбәрлек сүзләрнең кайберләре барлык/юклык, заман, килеш, тартым кебек категорияләр ала.

*Искәрмә*: Ф.М.Хисамова хәбәрлек сүзләрне модаль сүзләр составында карый; Ч.М.Харисова фикеренчә, алар мөстәкыйль һәм модаль сүзләр арасында тора; Татар грамматикасында хәбәрлек сүзләр мөстәкыйль сүз төркеме буларак тасвирлана.

Рус телендә бу төркем сүзләрдә дәрәҗә формалары кулланылу хас.

*Искәрмә*: Сыйфатның кыска формасы, -о формалы рәвешләр белән охшаш. Аларны аеру өчен сүзнең семантикасына карыйбыз, предикатив сүз халәтне (категория состояния) белдерә, җөмләдә хәбәр була, ә рәвеш – хәл була. Предикатив сүзләрнең *было холодно, станет тепло* кебек аналитик заман формалары бар, рәвешләрнең заман формасы булмый. Мәктәп программасында рәвеш буларак өйрәнелә.

Татар телендә хәбәрлек сүзләр төрле җөмлә кисәге булырга мөмкин. Мәсәлән, гади хәбәр: *Исем-фамилиясе юк*, сирәк кенә аергыч: *Юк йомышны бар итеп.*

Рус телендә гадәттә иясез җөмләнең хәбәре булып килә: *В комнате было красиво*.

**Бәйлек** (послелог) – предлог – семантик яктан грамматик мәгънә белдерә – сүзләр арасындагы мөнәсәбәтләрне оештыруда катнашалар. Функциональ яктан килешләр белән бәйле: *өйгә чаклы, кул белән, при доме, у костра һ.б.*

Морфологик яктан төрләнми, сүз ясагыч, форма ясагыч кушымчалар ялганмый. Предмет мәгънәсен белдергән сүзләр белән генә кулланыла.

Татар телендә бәйлекләр исемнең аерым килештә килүен таләп итә. Шул нигездә: баш яки иялек, юнәлеш, чыгыш килешне таләп итүче бәйлекләр дип төркемләнә.

Рус телендә Им.п. предлог белән кулланылмый, П.п. һәрвакыт предлог белән килә. Предлогның мәгънәсе билгеле бер килеш белән кулланылганда гына тулысынча ачыклана. Кайбер предлоглар берничә килеш формасы белән кулланылып, төрле мәгънә белдерергә мөмкин.

Синтаксик яктан үзе ияргән сүз белән бер җөмлә кисәге буларак карала. Татар телендә үзе ияргән сүздән соң килә, рус телендә үзе ияргән сүздән алда килә.

Ясалышы ягыннан:

1) саф / первичные: *белән, сыман, хәтле, таба, в, с, до, из, под* һ.б.

2) килеп чыгышы белән аерым сүз төркемнәренә бәйле / производные: *сәбәпле, аркылы, соң, карамастан, несмотря на, наперекор, сквозь, благодаря, в отличие от* һ.б.

Ике тел өчен дә уртак булган төркемчәләре:

- бергәлек: белән // *с, при*.

- сәбәп-максат: өчен, сәбәпле // *из-за, от, ради, благодаря, ввиду, вследствие, в силу, для, в целях, за, на, к* һ.б.;

вакыт: буе, саен, соң, элек һ.б. // *после, до, через, в течение, в продолжение, в, с, до* һ.б.;

урын: таба, аша // *перед, под, в, у, близ, около, на* һ.б.;

объект-корал: турында, белән // *о, по, за* һ.б.;

татар телендә охшату-чагыштыру: хәтле, кадәр;

рус телендә кире: *несмотря на, невзирая на*;

*Искәрмә*: ике телдә дә фәнни хезмәтләрдә мәгънә ягыннан бүленеш бер төрле генә түгел.

**Теркәгеч** – союз – сүзләрне, җөмләләрне үзара бәйли һәм төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен, ягъни грамматик мәгънә белдерә.

Морфологик яктан төрләнми. Синтаксик яктан үзе аерым җөмлә кисәге булып килә алмый. Төзелеше буенча гади (*һәм, ә*), кушма (*югыйсә, яисә*), кабатлаулы була (*әле…әле, ни…ни*).

Татар һәм рус телләрендә теркәгечләрнең төркемчәләре:

Тезүче / сочинительные:

- җыючы / соединительные: *һәм, да, дә / и, да, и… и, ни… ни*;

- каршы куючы / противительные: *ә, лəкин, тик* һ.б. / *а, но, однако, же, зато һ.б.;*;

- бүлүче: я, яки, яисә, ни…ни / разделительные: *или, или…или, либо, либо…либо*;

Болардан тыш рус телендә тезүче теркәгечләрнең түбәндәге төркемчәләре бар:

- кушучы / присоединительные: *причем, да и, также, тоже* һ.б.;

- чагыштыручы / сопоставительные: *не только, как… так и;*

- аныклаучы / пояснительные: *а именно, то есть.*

Татар телендә ияртүче: әгәр, гүя, гәрчә, югыйсә һ.б.

Рус телендә ияртүче теркәгечләр:

- ачыклаучы / изъяснительные: *что, чтобы*;

- вакыт / временные: *когда, пока, с тех пор как* һ.б.;

- сәбәп / причинные: *потому что, оттого что, так как, ибо* һ.б.;

- нәтиҗә / следствия: *так что*;

- шарт / условия: *если (ежели), коли*, раз һәм *кабы (сөйләм теленә хас)*;

- кире / уступительные: *хотя, несмотря на то что* һ.б.;

- максат / целевые: *чтобы (чтоб), для того чтобы, затем чтобы, с тем чтобы* һ.б.;

- чагыштыру / сравнительные: *как, словно, будто, точно, чем, как будто* һ.б.

*Искәрмә*: рус телендә төркемчәләрнең күплеге телнең типологиясе белән аңлатыла.

Теркәгеч һәм бәйлекләрнең уртаклыгы: сүзләр һәм җөмләләр арасында төрле мәгънә мөнәсәбәтләрен белдерә, аларны бәйли; икесе дә төрләнми, нигездә яңа сүз ясамый. Аерымлыгы: бәйлек үзе иярткән сүз белән бергә җөмлә кисәге булып карала, теркәгеч – синтаксик яктан мөстәкыйль, җөмлә кисәге составына кертелми, аерым карала. Мәгънәви яктан бәйлекләр бергәлек, корал, урын, вакыт, сәбәп, максат кебек мөнәсәбәтләр формалаштыра; теркәгечләргә санау, каршы кую кебек мәгънәләр белдерү хас.

**Кисәкчә** – частица – сүзләргә, җөмләләргә модаль-экспрессив (үтенү, сорау, раслау, шикләнү) мәгънә төсмере өсти, мәгънәне чикли, көчәйтә. Ике телдә дә кисәкчәләр препозитив (*әллә, что за*) һәм постпозитив (*-мыни, -ка*). Рус телендә сүз ясагыч һәм форма ясагычка бүлеп карала. Татар телендә форма ясагыч кушымчаларга якын дип карала, ләкин семантик үзенчәлеге нигезендә модаль мәгънәле сүз төркеме буларак өйрәнелә. Мөстәкыйль җөмлә кисәге була алмый.

Татар телендә мәгънә ягыннан төркемчәләре:

Раслаучы: *бит, ич, ләбаса*;

Инкарь итүче: *түгел, һич*;

Чикләүче: *гына/генә, кына/кенә*;

Көчәйтүче: *иң, үтә, кып-* һ.б.;

Билгесезлек: *әллә, -дыр/-дер*;

Сорау: *-мы/-ме, -мыни/-мени*;

Үтенү: *-чы, -сана, инде, әле*;

Аныклаучы: *нәкъ, тап*;

Урын-ара, вакыт мәгънәсен көчәйтүче: *ук, үк*.

Рус телендә мәгънә ягыннан төркемчәләре:

Модаль кисәкчәләр:

Раслаучы / утвердительные: *да, так, точно, ага, угу, а как же, как же* һ.б.;

Инкарь итүче / отрицательные: *не, ни, нет, вовсе не, отнюдь нет, далеко не* һ.б.;

Сорау / вопросительные: *что, ли, разве, неужели, а, да, что ли* һ.б.;

Чагыштыручы / сравнительные: *как, как бы, словно, будто, точно, вроде* һ.б.;

Шик мәгънәсен белдерүче / авторизационные: *мол, -де, дескать, якобы* һ.б..

Модаль булмаган кисәкчәләр:

- рациональ:

күрсәтү / указательные: *вот, вон, это, оно*;

билгеләү-аныклау кисәкчәләре / определительно-уточняющие: *точно, именно, ровно, как раз, подлинно, почти, примерно, чуть не* һ.б.;

чикләүче / выделительно-ограничительные: *лишь, только, только лишь, разве лишь, всё, исключительно, единственно, всего, всего-навсего, хоть, хотя бы* һ.б.;

көчәйтүче / усилительные: *даже, даже и, же, и, ведь, уже (уж), ну, ни, ещё, то, просто, прямо* һ.б.

- эмоциональ-экспрессив: *что за, как, вот так, куда, где там, то-то, ну и, куда как* һ.б.

**Ымлык** – междометие – хис-тойгы, эчке кичереш, ихтыярны атамыйча белдерә торган сүзләр төркеме. Морфологик яктан төрләнми, кайбер ымлыклардан сүз ясалырга мөмкин. Синтаксик яктан татар телендә җөмлә кисәге була алмый, аерым җөмлә төзи ала. Рус телендә аерым очракларда җөмләдә ия, хәбәр, иярчен җөмлә булырга мөмкин.

Мәгънә ягыннан төрләре.

Татар телендә:

а) хис-тойгыны белдерә торган эмоциональ ымлыклар:

- шатлык, соклануны;

- үкенү, рәнҗү, зарлануны;

- курку, шомлану, гаҗәпләнү;

- искитмәү, кимсетү;

- ярсу, канәгатьсезлек, ачулану;

- исәнләшү, гафу үтенү һ.б.

б) ихтыярны белдерә торган императив ымлыклар: боеру, тыю, чакыру, эндәшү, өндәү кебек мәгънәләрне белдерә; кош-корт, хайваннарны чакыру сүзләре дә монда карала.

Рус телендә:

а) эмоциональ ымлыклар: *а, ай-яй-яй, ах, э, эге, о, ого, огого, м-да, фи, фу, гм, тьфу* һ.б.;

*Искәрмә*: әлеге төркемне шулай ук шатлык, кайгы, борчу, курку, канәгатьсезлек белдерү, сарказм кебек мәгънә белдерүләренә карап төркемләгән хезмәтләр дә бар.

б) императив (боеру) ымлыклары: *айда, марш, на, стоп, тпру* һ.б.;

в) этикет ымлыклары: *здравствуйте, до свидания, спасибо, пожалуйста, не стоит, спокойной ночи, будьте любезны* һ.б.

**Модаль сүзләр** – модальные слова – сөйләүченең хәбәр ителә торган фикергә мөнәсәбәтен белдерүче сүзләр төркеме.

Модаль сүзләр төрләндергеч һәм ясагыч кушымчалар кабул итми. Җөмлә кисәге була алмый һәм җөмләдәге башка сүзләр белән грамматик бәйләнешкә керми. Синтаксик яктан модаль сүзләр кереш сүз һәм сүз-җөмлә функциясен башкара.

Мәгънә төсмерләре буенча төркемчәләре.

Татар телендә:

1) фикернең чынлыгын катгый раслый торган: *әлбәттә, шиксез, тәгаен, мәгълүм ки* һ.б.;

2) фикер чынлыгы фараз кылу яки икеләнү төсмере белән белдерә торган: *бугай, шаять, ихтимал, ахрысы, күрәсең* һ.б.

*Искәрмә*: рус телендәге бүленеш белән татар телендәге бүленеш туры килмәгән очраклар бар. Мәсәлән, 2, 4 пунктлар кереш сүз булса да, татар телендә модаль сүз буларак каралмый.

Рус телендә:

1) фикернең дөреслеген яки дөрес түгеллеген белдерә торган: *конечно, бесспорно, разумеется, действительно, несомненно, без-условно, очевидно, возможно, вероятно, наверное, видимо, кажется, может быть, видно, пожалуй, һ.б.*;

2) фикер дөреслеген чыганак белән бәйле торган: *говорят, по-моему, по слухам* һ.б.;

3) фикергә эмоциональ бәя бирә торган: *ко всеобщему восхищению, к сожалению, к счастью, к несчастью, к удивлению һ.б.*;

4) фикерне иншалау тәртибен белдерә: *во-первых, кроме того, наконец, напротив, наоборот, однако, так сказать* һ.б. һәм мәгълүматны чикли яки өсти, аныклый торган: *итак, кстати, например, в частности, впрочем, словом, иначе говоря, следовательно, значит* һ.б.;

5) тыңлаучы белән сөйләүче арасында контакт урнаштыра торган сүзләр: *видите ли, понимаешь, слышишь, представляете* һ.б.

## СИНТАКСИС

**Тезүле бәйләнеш** – сочинительная связь.

Татар телендә *тезүче, каршы куючы, бүлүче теркәгечләр; санау, каршы кую паузасы* ярдәмендә формалаша.

Рус телендә *интонация* һәм *теркәгечләр:* ябык тезүле бәйләнеш (ике компонент бәйләнешкә керә) *каршы куючы (противительные), градацион, ачыклаучы;* ачык тезүле бәйләнеш (компонентлар чиге билгеләнми) *теркәгечсез (җыю мәгънәсе), җыючы, бүлүче теркәгечләр* ярдәмендә урнаша.

**Ияртүле бәйләнеш** – подчинительная связь.

Чагыштырыла торган телләр өчен хас булган *синтаксик мөнәсәбәт* төрләре:

Татар телендә. *Хәбәрлекле мөнәсәбәт* һәм аны белдерү чаралары: хәбәрлек, зат-сан, -нык ы/-неке, Ч.к., Ю.к., У-в.к. кушымчалары, сүз тәртибе, интонация, сәбәп-максат, чагыштыруны белдерүче бәйлекләр;

*Төгәлләүле мөнәсәбәт* һәм аны белдерү чаралары: килеш, хәл фигыль, шарт фигыль, инфинитив, сыйфат фигыль, кайбер сыйфат һәм рәвеш ясагыч кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр, сүз тәртибе, янәшәлек, фраза басымы, сүзләр кабатлану, лексик мәгънә;

*Аныклаулы мөнәсәбәт* һәм аны белдерү чаралары: аныклаулы теркәгечләр һәм теркәгеч сүзләр, аныклау интонациясе.

Рус телендә: *Предикатив мөнәсәбәт* – ия һәм хәбәр мөнәсәбәте.

*Атрибутив* – ияртүче сүз предмет, иярүче сүз аның билгесен белдергәндә формалаша.

*Объектив* – ияртүче сүз билге, хәрәкәт, халәтне, ияртүче сүз әлеге билге юнәлгән предметны белдергәндә формалаша.

*Релятив* – ияртүче сүз билге, процесс, хәрәкәтне, иярүче сүз билгене белдерә.

*Субъектив* – ияртүче сүз хәрәкәт, халәт, билгене, ә иярүче сүз әлеге хәрәкәт, билге, халәт субъектын белдерә.

*Аппозитив* – предмет һәм аның белән бәйле ике төшенчә мөнәсәбәте.

*Синтаксик чараларның* төрләре.

*Ярашу – согласование.* Татар телендә тулысынча ярашу аныклагыч белән аныкланмыш арасында гына күзәтелә; ия белән хәбәр арасында һәрвакыт тулы булмый. Рус телендә тулы һәм өлешчә ярашу була. Тулы булганда, компонентлар барлык грамматик категорияләрдә дә яраша; өлешчә ярашу булганда кайсы да булса бер категориядә ярашмый кала.

*Башкарылу – управление.* Татар телендә башкарылу булганда ияртүче сүз иярүченең нинди дә булса килеш формасын алуын, яки кайсы да булса бәйлек белән килүен таләп итә. Рус телендә көчсез / слабое һәм көчле / сильное төрләре карала. Көчле башкарылу булганда, күчемле фигыльләр Р.п., В.п. исемнәр белән кулланыла; көчсез башкарылу булганда – фигыль белән хәл килешләр кулланылып, объект һәм хәл мәгънәсе бергә килә.

*Янәшәлек – примыкание*. Татар телендә ярашу да, башкарылу да булмаган очрак. Хәл фигыль, шарт фигыль, сыйфат фигыль, кайбер сыйфат һәм рәвеш ясаучы, тартым кушымчалары, мөнәсәбәтле сүзләр, ияртүче теркәгечләр, сүз тәртибе, интонация, янәшә тору һәм лексик мәгънә аша бәйләнешләр керә. Рус телендә төрләнми торган сүзләр арасында урнаша. Ияруче сүз ролендә рәвеш, инфинитив, хәл фигыль, рәвеш яки сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе, төрләнми торган сыйфатлар килә.

Татар телендә сүзләр бәйләнешен анализлаган вакытта компонентлар арасында нинди мөнәсәбәт урнашу мөһим булса, рус телендә сүзләр бәйләнешендә род, сан, килеш категорияләрендә ярашу әһәмиятле булып, бәйләүче чараны күрә белү кирәк.

**Сүзтезмә** – словосочетание. Ике телдә дә сүзтезмәләр төзелеше белән гади яки катлаулы, ирекле яки фразеологик була. Ияртүче сүз җөмләнең теләсә кайсы кисәге була ала, ияруче сүз иярчен кисәк кенә була. Шуңа нигезләнеп, татар һәм рус телләрендә сүзтезмәләрнең түбәндәге төрләре аерып карала:

| **ФИГЫЛЬ СҮЗТЕЗМӘЛӘР – ГЛАГОЛЬНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** | |
|---|---|
| исемле (алмашлык, сан, сыйфат, сыйфат фигыль, исем фигыль) фигыль сүзтезмә: *аңа сөйләү, укыганны ярату һ.б.* | фигыль, сыйфат фигыль яки хәл фигыль + исемле фигыль сүзтезмә: *работать с детства, рубить топором и т.д* |
| санлы фигыль сүзтезмәләрдә сан үзенең туры мәгънәсендә килеп, | фигыль, сыйфат фигыль яки хәл фигыль + рәвешле фигыль |

| | |
|---|---|
| мәртәбә, тапкыр, кат, итеп һ.б. сүзләре аша иярә: *беренче итеп язу, өчәр мәртәбә бару һ.б.* | сүзтезмә: *писать красиво, читать быстро, поступать справедливо и т.д.* |
| рәвешле һәм сыйфатлы фигыль сүзтезмәләр: *ялгыз калу, матур киенү, зур итеп төяү һ.б.* | фигыль, сыйфат фигыль яки хәл фигыль + инфинитивлы фигыль сүзтезмә: *просить спеть, предложить выучить и т.д.* |
| фигыльле фигыль сүзтезмә: *әйтмәкче булып авыз ачу, кайткач күрү, утырган көйгә йоклау һ.б.* | фигыль, сыйфат фигыль яки хәл фигыль + хәл фигыльле фигыль сүзтезмә: *идти оглядываясь, говорить улыбаясь и т.д.* |
| **ИСЕМ СҮЗТЕЗМӘЛӘР – ИМЕННЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ (СУБСТАНТИВ)** | |
| исемле исем сүзтезмә: *батырның бүләге, ут яктысы, куян йөрәк һ.б.* | сыйфатлы исем сүзтезмә: *красивое пальто, интересная книга, полезный совет и т.д.* |
| сыйфатлы һәм рәвешле исем сүзтезмә: *изге күңел, нык кул, язгы кояш һ.б.* | сыйфат фигыльле исем сүзтезмә: *читающая девочка, выполненная работа и т.д.* |
| санлы исем сүзтезмә: *җиде ел, беренче баскыч, икешәр конфет һ.б.* | санлы исем сүзтезмә: *первая любовь, вторая аудитория и т.д.* |
| фигыльле исем сүзтезмә: *утын кискән пычкы, арган кыяфәт, кайтырга теләк, уйнарга исәп һ.б.* | исемле исем сүзтезмә: *человек с характером, письмо родителям, дом с балконом и т.д.* |
| хәбәрлек сүзле исем сүзтезмә: *кирәк кадәр су, тикшерелергә тиешле эш һ.б.* | рәвешле исем сүзтезмә: *торговля оптом, прогулка верхом, карп по-индийски и т.д.* |
| - | алмашлыклы исем сүзтезмә: *твоя невеста, наша страна и т.д.* |
| - | инфинитивлы исем сүзтезмә: *мечта жить, желание учиться, умение рисовать и т.д.* |
| **СЫЙФАТ СҮЗТЕЗМӘЛӘР – АДЪЕКТИВНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** | |
| исемле сыйфат сүзтезмә: *тумыштан сукыр, биюгә оста, уртасыннан сынык һ.б.* | исемле сыйфат сүзтезмә: *темный от загара, достойный похвалы, довольный ответом и т.д.* |
| рәвешле сыйфат сүзтезмә: | алмашлыклы сыйфат сүзтезмә: |

| | |
|---|---|
| *бөтенләй яхшы, уттай кызу һ.б.* | *довольный всем и т.д.* |
| фигыльле сыйфат сүзтезмә: *йөрергә яхшы, кияргә уңай, эшләгәнгә күрә нык һ.б.* | рәвешле сыйфат сүзтезмә: *по-весеннему светло, умеренно холодный, очень интересный и т.д.* |
| - | инфинитивлы сыйфат сүзтезмә: *готовый улыбнуться, способный работать и т.д.* |
| **АЛМАШЛЫК СҮЗТЕЗМӘ – МЕСТОИМЕННЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** | |
| *Дусларымның берсе, укучыларымнан ул һ.б.* | *Кто-то из студентов, нечто новое и т.д.* |
| **САН СҮЗТЕЗМӘЛӘР – НУМЕРАТИВНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** | |
| *Ахырдан алтынчы, укучылардан берәү, укучы белән ун, минем өчен бер һ.б.* | Исемле яки алмашлыклы сан сүзтезмә: *первый в ряду, оба друга, две книги и т.д.* |
| **РӘВЕШ СҮЗТЕЗМӘЛӘР – НАРЕЧНЫЕ СЛОВОСОЧЕТАНИЯ** | |
| Рәвешләр рәвеш һәм исемне ияртә: *бүген иртән, иртәгә кичен, кошлардан җитезрәк, поездддан тизрәк һ.б.* | Исемле яки рәвешле рәвеш сүзтезмә: *очень тихо, по-прежнему хорошо, незадолго до экзаменов и т.д.* |
| **ХӘБӘРЛЕК СҮЗЛЕ СҮЗТЕЗМӘЛӘР** | |
| *Укытучы өчен кирәк, миңа мөмкин, анда бар, аңа юк һ.б.* | - |

**Җөмлә кисәкләре** – члены предложения. Татар һәм рус телләрендә җөмләнең баш кисәкләре: *ия / подлежащее, хәбәр / сказуемое*.

*Искәрмә*: Рус телендә исемләшкән сыйфатлар ия ролендә татар теленә караганда ешрак кулланыла.

Татар телендә *гади фигыль хәбәр, гади исем хәбәр; тезмә фигыль, тезмә исем хәбәр* (таркалмый торган тезмә белән); *кушма фигыль хәбәр* (гади яки тезмә хәбәр + ярдәмче фигыль), *кушма исем хәбәр* (фигыльдән кала сүз төркемнәре + ярдәмче фигыль) формалары; рус телендә *гади фигыль хәбәр* (катлауландырылган / осложненное яки катлауландырылмаган / неосложненное глагольное сказуемое); *тезмә фигыль хәбәр* (затланышлы фигыль + инфинитив), *тезмә исем хәбәр* (исем, сыйфат, алмашлык, сыйфат фигыль + бәйләгеч); *кушма фигыль хәбәр, кушма исем хәбәр; катнаш кушма хәбәр* (өч, күп компонентлы) формалары кулланыла.

*Иярчен кисәкләр* – аергыч / определение, тәмамлык / дополнение, хәл / обстоятельство. Аергыч җөмләдә сыйфат, сан, алмашлык, сыйфат фигыль белән белдерелә. Туры һәм кыек тәмамлыклар була. Рәвеш / образа действия, вакыт / времени, урын / места, күләм / меры и степени, сәбәп / причины, максат / цели, шарт / условия, кире / уступки хәлләр бар.

Татар телендә исем белән белдерелгән аергычлар типологик үзенчәлек булып тора, рус телендә алар сыйфат белән белдерелгән аергычка туры килә. Аергыч рәвеш, инфинитив, хәбәрлек сүз белән дә белдерелергә мөмкин. Аергычның рус телендәге өстәлмә төре татар теленә гади аергыч буларак тәрҗемә ителә.

Рус телендә аергыч белән аерылмышның ярашкан булу / булмавын билгеләү мәҗбүри. Аерылмышның ярашкан, ярашмаган, өстәлмә (үзе ярашкан, ярашмаган була) дигән төрләре бар. Ярашмаган аергыч исем, инфинитив, рәвеш белән белдерелә. Обстоятельство следствия (нәтиҗә хәле) аерым өйрәнелә.

*Модаль кисәкләр* – эндәш сүз / обращение, кереш сүзләр / вводное слово. Кереш сүзләр күп төрле мәгънә мөнәсәбәтләре белдерәләр.

Чагыштырыла торган телләрдә баш кисәкләр дә, иярчен кисәкләр дә тиңдәш була ала. Аерымланган кисәкләр җөмләнең синтагматик бүленешенә нигезләнгәннәр, алар синтагманың традицион рәвештә тыныш билгеләре белән аерыла торганнарын гына үз эченә ала, тыныш билгесе белән аерылмый торган синтагмалар аерымланган кисәк дип саналмыйлар.

Структур-семантик яктан ике телдә дә җөмлә кисәкләре *предикат, субъект, объект, атрибут, квалификатор*га бүленә.

Актуальлек ягыннан *тема* һәм *рема* аерып карала. Тема – сөйләм предметын, рема – сөйләм яңалыгын белдерә. Актуаль кисәкләргә бүленеш сөйләм процессында сүз тәртибе, интонация ярдәмендә белдерелә һәм сөйләүченең нәрсә әйтергә теләвенә бәйле. Шул сәбәпле, бер үк җөмлә актуаль кисәкләргә төрлечә бүленергә мөмкин. Актуаль кисәкләргә бүленеш һәм грамматик бүленеш бер-берсеннән бәйле түгел. Чөнки тема һәм рема аерым җөмлә кисәкләре белән туры килми.

**Җөмләдә сүз тәртибе** – порядок слов в предложении. Татар һәм рус телләрендә уңай һәм кире сүз тәртибе була. Сүз тәртибенең функцияләре: *коммуникатив* (хәбәр итү максатыннан чыгып, җөмләдә сүз тәртибенең әһәмияте); *синтаксик* (сүз тәртибенең сүзләр бәйләнешендә синтаксик чара буларак кулланылышы, ягъни сүз тәртибенең бәйләү көче кушымчаларга тиң булу); *стилистик* (сүз тәртибе үзгәрү нәтиҗәсендә аерым җөмлә кисәкләренең мәгънә төсмерләре үзгәрү мөмкинлеге). Сүз тәртибен билгеләү сөйләм төренә бәйле.

Хәбәрлекле мөнәсәбәт булганда, татар телендә ике очрак күзәтелә: сөйләм предметы – сөйләм яңалыгы, сөйләм предметы – сөйләм яңалыгы – сөйләм предметы (хәбәр) килә.

Предикатив мөнәсәбәттә рус телендә гадәти язма сөйләмдә сөйләм предметы, аннан соң сөйләм яңалыгы килә.

Ике телдә дә төгәлләүле мөнәсәбәттәге кисәкләрнең иярүчесе ияртүчедән алдан килә (аергыч аерылмыштан, тәмамлык һәм хәл ияртүче кисәктән алда куела).

Татар телендә аныклагыч белән аныкланмышның урынын үзгәртү функция үзгәрүгә китерә.

Рус телендә ярашмаган аергыч аерылмыштан соң куела.

Игътибар җәлеп итү максатыннан әйтелгәндә, *эндәш сүз* җөмлә башында куела. *Кереш сүз* тулаем җөмләгә дә, аерым сүзгә дә карарага мөмкин. Тиңдәш ияләр, аергычлар, тәмамлыклар, хәлләр, гадәттә, урын сайламыйлар. Әгәр тиңдәш хәбәрләр параллель күренешләрне белдерсәләр, аларның гомумирәк эшне белдерә торганнары башта әйтелә, калганнары соңыннан килә; эзлекле күрнешләрне белдерсәләр, алар шул эзлеклелеккә карап урнашалар. Гадәттә җөмлә башында яки ахырында килә торган җөмлә кисәге урынын алыштырып кулланылса, кире сүз тәртибе була. Аныклагыч һәм аныкланмыш, модаль кисәкләрдә инверсия күренеше булмый.

**Җөмлә төрләре**. Җөмләләрне төркемләү принциплары чагыштырыла торган телләрнең икесе өчен дә уртак:

- хәбәрлек составына карап: гади (простое), кушма (сложное);

- иярчен кисәк булу / булмауга карап: җыйнак (нераспространенное), җәенке (распространенное);

- мәгънә тулылыгы өчен кирәкле кисәкләрнең булу / булмавына карап: тулы (полное), ким (неполное);

- оештыручы үзәкнең санына карап: бер составлы (односоставное), ике составлы (двусоставное);

- әйтү максатыннан: хикәя (повествовательное), сорау (вопроси-тельное), боерык (побудительное), тойгылы (восклицательное);

- чынбарлыктагы күренешләрне раслау яки инкарь итүгә бәйле: раслау (утвердительные), инкарь (отрицательные).

## КУШМА ҖӨМЛӘ – СЛОЖНЫЕ ПРЕДЛОЖЕНИЯ

**Тезмә кушма җөмлә** – сложносочиненное предложение. Татар телендә бу төр җөмләләрнең 1) теркәгечле (җыючы, бүлүче, каршы куючы теркәгечләр ярдәмендә төзелә) һәм 2) теркәгечсез (санау, каршы кую интонациясе ярдәмендә төзелә) торган төрләре бар.

Рус телендә алар 1) теркәгечле:

а) <u>ачык төзелешле</u> (открытой структуры) тезмә кушма җөмлә:

- җыю мөнәсәбәтен белдерә (соединительные отношения);
- бүлү мөнәсәбәтен белдерә (разделительные отношения);

б) <u>ябык төзелешле</u> (закрытой структуры) тезмә кушма җөмлә:

- каршы кую мәгънәсен белдерә (противительные отношения);
- кушу мәгънәсен белдерә (присоединительные отношения);
- аныклаулы мөнәсәбәт белдерә (пояснительные отношения) була. Терминнардан аңлашылганча, шулай ук атала торган теркәгечләр ярдәмендә төзеләләр. Соңгы ике төр рус теленең үзенчәлекле күренеше булып тора.

**Иярченле кушма җөмлә** – сложноподчиненное предложение. Татар телендә иярчен җөмләләрнең баш җөмләгә нинди чарар ярдәмендә иярүенә бәйле аналитик һәм синтетик төрләре бар. Аналитик иярчен җөмләләр баш җөмләгә хәбәр составыннан читтә булган ияртүче теркәгечләр, ялгызак һәм парлы мөнәсәбәтле сүзләр, көттерү паузасы ярдәмендә иярә. Синтетик иярчен җөмлә баш җөмләгә кушымчалар, бәйлек һәм бәйлек сүзләр ярдәмендә иярә.

Рус телендә кушма җөмләләр аналитик төзелешле генә була. Аналитик иярчен җөмлә / придаточная часть баш җөмләгә теркәгеч һәм теркәгеч сүзләр ярдәмендә иярә.

Моннан тыш рус телендә мөстәкыйль карала торган теркәгечсез / бессоюзное җөмләләр дә бар. Бу очракта аерым җөмләләр мәгънә, интонация, сүз тәртибе, фигыль-хәбәрнең вид-заман формалары ярдәмендә ялгана. Теркәгечсез кушма җөмләләр үзләре берничә төрле була:

- теркәгечле кушма җөмләләргә нисбәтле булмаган (сирәк);
- теркәгечле кушма җөмләләргә нисбәтле:

а) бер типтагы өлешләрдән тора (однородного состава) – тезмә кушма җөмләгә якын;

б) төрле типтагы өлешләрдән тора (неоднородного состава) – иярченле кушма җөмләгә якын.

Рус телендә иярченле кушма җөмлә таркала торган (расчлененное / двучленное – иярчен җөмлә тулаем баш җөмләгә карый) һәм таркалмый торган (нерасчлененное / одночленное – иярчен җөмлә аерым бер сүзгә яки сүзтезмәгә карый) төрләргә бүленә.

*Искәрмә*: Татар теленә аналитик иярчен һәм тезмә дә булган кушма җөмлә конструкциясе хас.

Мәгънә һәм функция ягыннан ике тел өчен дә уртак булган иярчен җөмлә төрләре: *тәмамлык / изъяснительное (повествовательное, вопросительное)*, *аергыч / определительное*, *аныклагыч / пояснительное*, хәл (*вакыт / времени*,

*урын / места, рәвеш / образа действия, күләм / меры и степени, сәбәп / причины, максат / цели, шарт / условия, кире / уступки*).

Иярчен ия, хәбәр, кереш җөмләләр татар теле үзенчәлеге булып тора.

Иярчен *чагыштырма* / сравнения, *сәбәп-нәтиҗә* / следствия, *өстәлмә* / присоединения, *капма-каршы* / сопоставления җөмләләр рус теленә генә хас дип карала.

Татар телендә синтетик иярчен җөмләләр, ияручe кисәк ияртүче кисәктән алда килгәнлектән, баш җөмләдән алда килә; аналитик җөмләләр баш җөмләдән алда да, соң да килергә мөмкин.

Рус телендә иярчен җөмлә кушма җөмләнең теләсә кайсы урынында килергә мөмкин.

Ике телдә дә:

- күп иярченле (тиңдәш ияругле (с однородным подчинением) һәм тиңдәш булмаган иярүле (с неоднородным подчинением)) кушма җөмләләр;
- катнаш кушма җөмләләр бар.

## ЧАГЫШТЫРМА АСПЕКТТА АНАЛИЗ ҮРНӘКЛӘРЕ

1. Чагыштырма фонетик анализ

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| иҗек саны, аның төре; басым, аның төре | |
| *көн [к ө' н]; бер иҗек, ябык, каплаулы; басым хәрәкәтчән* | *день [д' э' н']; бер иҗек, ябык, каплаулы; басым хәрәкәтчән* |
| хәрефләр, аларның саны; авазлар, аларның саны | |
| *3 хәреф, 3 аваз* | *4 хәреф, 3 аваз* |
| һәр сузык авазга тулы характеристика;<br>татар телендә сүз сингармонизм законына буйсынамы | |
| *[ө] – алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшкән, кыска* | *[э] – алгы рәт, урта күтәрелеш, иренләшмәгән, киң әйтелешле* |
| һәр тартык авазга тулы характеристика | |
| *[к] – тел алды, йомык, саңгырау, яңгырау пары [г]*<br>*[н] – тел алды тел-теш, ярым йомык, борын, сонор* | *[д'] – тел алды тел-теш, фомык, яңгырау, саңгырау пары [т], нечкә*<br>*[н'] – тел алды теш, ярым йомык, борын, сонор, нечкә* |
| ике телдә дә бер үк хәреф белән белдерелгән авазларга чагыштырма анализ | |
| *“н” хәрефе белән белдерелгән авазларда аерма бар, рус телендә авазның нечкә варианты кулланылган* | |
| әйтелеш белән язылыш туры киләме, килмәгән очракларны аңлатырга | |

| | |
|---|---|
| *әйтелеш белән язылыш туры килә* | *үзенчәлекле нечкә вариантны белдерү өчен "ь" билгесе кулланылган* |

2. Сүз төзелешенә чагыштырма анализ

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме билгеләнә | |
| *көзге (яфрак) - сыйфат* | *осенний (листок) - сыйфат* |
| сүзнең тамыры билгеләнә, ул мөстәкыйль лексик берәмлек була аламы | |
| *көз, мөстәкыйль сүз була ала* | *осен'-, мөстәкыйль була* |
| сүзнең нигезе, аның төре күрсәтелә | |
| *көзге, ясалма нигез* | *осенн-, ясалма нигез* |
| аффиксларга характеристика бирелә | |
| *-ге сүз ясагыч кушымча, исемнән сыйфат ясый* | *-н- сүз ясагыч суффикс, -ij төрләндергеч кушымча* |

3. Чагыштырма морфологик анализ

1) исем сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Ильяс мәктәптә укый. – Ильяс учится в школе.*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, сүзнең башлангыч формасы* | |
| *тамыр исем, мәктәптә (укый)* | *исем, школа* |
| лексик-грамматик төркеме | |
| *уртаклык, конкрет* | *уртаклык, конкрет* |
| килештә | |
| *урын-вакыт килешендә* | *предложный падеж* |
| сан | |
| *берлек сан* | *берлек сан* |
| тартым | |
| *тартымсыз* | - |
| хәбәрлек | |
| *хәбәрлексез* | - |
| җанлы / җансыз | |
| - | *җансыз (неодушевленное)* |
| грамматик җенес (род) | |
| - | *женский родта* |
| төрләнеш – склонение | |

| | |
|---|---|
| - | *беренче склонение* |
| синтаксик функциясе | |
| *урын хәле* | *урын хәле* |

* татар телендә исем үзе бәйләнгән сүз белән карала, ясалышы билгеләнә; рус телендә - И.п., берлек сан формасы була;

2) сыйфат сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Язгы кояшның беренче нурлары – Первые лучи весеннего солнца.*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, сүзнең башлангыч формасы* | |
| *ясалма сыйфат, язгы* | *сыйфат, весенний* |
| лексик-грамматик төркемчә | |
| *нисби* | *нисби (относительное)* |
| дәрәҗә | |
| *төп* | - |
| исемләшү / исемләшмәү | |
| *исемләшмәгән* | - |
| тулы / кыска форма | |
| - | - |
| исем белән ярашу / ярашмау | |
| - | *берлек сан, средний род, р.п.* |
| синтаксик функциясе | |
| *аергыч, язгы (кояшның)* | *солнце сүзенә бәйле, какого соравына җавап бирә, аергыч* |

* татар телендә сыйфатның ясалышы билгеләнә; рус телендә - И.п., берлек сан, муж.р. формасы була

3) сан сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Кышның беренче көннәре үзен сиздерә башлады – Первые дни зимы дают о себе знать*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, сүзнең башлангыч формасы* | |
| *ясалма сан, беренче (көннәр)* | *сан, первый* |
| лексик-грамматик төркемчә | |
| *тәртип* | *тәртип* |
| төзелеше | |
| *гади, исемне ачыклый* | *гади* |
| килеш | |

| | |
|---|---|
| - | *И.п.* |
| сан | |
| - | *Мн.ч.* |
| грамматик җенес (род) | |
| - | - |
| синтаксик функциясе | |
| *аергыч, беренче (көннәре)* | *дни сүзенә бәйле, аергыч* |

* рус телендә И.п. формасы алына;

4) алмашлык сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Ул көчле тавыш белән сөйли башлады – Он начал громко говорить*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, сүзнең башлангыч формасы* | |
| *алмашлык* | *алмашлык* |
| лексик-семантик төркемчә | |
| *зат* | *зат* |
| нинди сүз төркемен алыштыра | |
| *исемне* | *исемне (предметно-личное)* |
| зат | |
| *III зат* | *III зат* |
| сан | |
| *берлек* | *берлек* |
| килеш | |
| *Б.к.* | *Им.п.* |
| *грамматик җенес (род)* | |
| - | *Муж.р.* |
| синтаксик функциясе | |
| *ия* | *ия* |

* рус телендә им.п., берлек сан

5) фигыль сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Тилгән бер бәбкәне эләктерде – Ворон схватил одного гусенка.*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, сүзнең башлангыч формасы | |
| *фигыль, эләк-* | *фигыль, схватить* |
| *ясалыш ысулы* | |
| *тамыр нигезле* | - |
| заман, мәгънәсе | |

| | |
|---|---|
| *билгеле үткән заман* | *сов.вид үткән заман* |
| зат-сан | |
| *III зат, берлек сан* | * |
| юнәлеш | |
| *йөкләтү* | *төп* |
| наклонение | |
| *хикәяләү* | *хикәяләү* |
| күчемле / күчемсез | |
| *күчемле* | *күчемле* |
| кайтымлы / кайтымсыз | |
| - | *кайтымсыз* |
| дәрәҗә | |
| *кинәтлек* | - |
| барлык / юклык | |
| *барлыкта* | - |
| вид | |
| - | *сов. вид* |
| грамматик җенес - род | |
| - | *муж.род* |
| класс | |
| - | *продуктив* |
| төрләнеш – спряжение | |
| - | *II спр.* |
| синтаксик функция | |
| *хәбәр* | *хәбәр* |

* рус телендә үткән заман фигыль формасында зат билгеләнми

6) рәвеш сүз төркеменә чагыштырма морфологик анализ

*Ул Тукай урамын тиз тапты – Он быстро нашел улицу Тукая.*

| **Татар телендә** | **Рус телендә** |
|---|---|
| сүз төркеме, ясалыш буенча нигез төре | |
| *тамыр рәвеш* | *рәвеш* |
| мәгънә төркемчәсе | |
| *билге (үтәлү рәвешен белдерә)* | *билге (сыйфатлау – качественное)* |
| дәрәҗә | |
| *төп* | *төп* |
| синтаксик функциясе | |

| *рәвеш хәле* | *рәвеш хәле* |
|---|---|

## БЕЛЕМНӘРНЕ ТИКШЕРҮ ӨЧЕН ТЕСТЛАР

## Тема: «Чагыштырма тел белеме» курсына кереш. Тәрҗемә. Татар һәм рус телләре фонетикасы, лексикологиясе

**Типологик яктан дөнья телләре ничә төркемгә бүленә?**
А) 3 төркемгә;
Б) 2 төркемгә;
В) 4 төркемгә;
Г) 6 төркемгә.
**Татар һәм рус телләренең типологик үзенчәлекләре нинди?**
А) ике тел дә флектив;
Б) рус теле полисинтетик, татар теле аморф;
В) ике тел дә агглютинатив;
Г) татар теле агглютинатив, рус теле флектив.
**«Чагыштырма грамматика» курсының максаты нинди?**
А) татарча сөйләшергә өйрәтү;
Б) ике телнең уртак, аермалы, охшаш үзенчәлекләрен анализларга өйрәнү;
В) рус теле үзенчәлекләрен өйрәнү;
Г) татар теленең рус теленнән аерымлыкларын табу.
**Татар һәм рус телләрендә ничә тартык аваз бар?**
А) татар телендә - 27, рус телендә - 33;
Б) татар телендә - 28, рус телендә - 37;
В) татар телендә - 33, рус телендә - 41;
Г) ике телдә дә төгәл билгеле түгел.
**Татар һәм рус телләрендә басымның характеры?**
А) татар телендә даими, рус телендә күчемсез басым;
Б) рус телендә тотрыклы, татар телендә ирекле басым;
В) рус телендә төрле урынлы, күчемле, татар телендә даими;
Г) ике телдә дә басым әһәмиятле.
**Алынмаларның үзләштерелешендә нәрсә әһәмиятле?**
А) калькалаштыру;
Б) мәгънә саклану;
В) лексик-семантик, фонетик, морфологик принциплар;
Г) лексик берәмлекнең бөтенлеге.
**Сүзнең этимологиясен билгеләү өчен төп чыганаклар?**
А) сүзлек, фольклор, кардәш һ.б. телләр, язма истәлек;
Б) халык сөйләм теле һәм әдәбият;

В) тарихи фактлар;

Г) милли менталитет.

**Чагыштырма-типологик тел белеме кайчан барлыкка килгән?**

А) XX гасыр башында;

Б) XIX гасырда;

В) XVII гасырда;

Г) бүгенге көннәрдә.

## Тема: Чагыштырыла торган телләрдә сүз төзелеше, сүз ясалышы; исем, сыйфат, сан, алмашлык, рәвеш, бәйләгеч һәм модаль мәгънәле сүз төркемнәре

**Грамматик мәгънәне белдерү үзенчәлекләренә карап татар һәм рус телләре нинди төргә карый?**

А) татар теле синтетик, рус теле аналитик;

Б) татар теле дә, рус теле дә аналитик;

В) татар теле аналитик, рус теле синтетик;

Г) ике тел дә бер үк вакытта аналитик һәм синтетик.

**Грамматик мәгънә белдерүче аналитик чараларны билгеләгез.**

А) ярдәмче сүзләр, сүз тәртибе, интонация;

Б) интонация, эчке флексия, басым;

В) кушымчалар, суффикслар, интерфикслар;

Г) постфикс, сүз тәртибе, аффикслау, супплетивизм.

**Рус телендә морфемаларның төрләрен билгеләгез.**

А) тамыр, аффикс;

Б) тамыр, префикс, интерфикс, суффикс, окончание, постфикс;

В) окончание, тамыр, нигез;

Г) бәйләгеч, модаль, сүз ясагыч.

**Флексия нәрсә ул?**

А) сүз төрләндергеч аффикс;

Б) сүз ясагыч суффикс;

В) сүз төрләндергеч суффикс;

Г) сүз нигезе.

**Татар һәм рус телләрендә бер кушымча ничә мәгънә белдерә ала?**

А) татар телендә бер мәгънә, рус телендә ике мәгънә;

Б) татар телендә бер мәгънә, рус телендә күп мәгънә;

В) ике телдә дә бер генә мәгънә;

Г) ике телдә дә берничә мәгънә.

**<u>Разговориться, подорожник</u> сүзләре нинди ысул белән ясалган?**

А) постфиксация;

Б) аббревиация;
В) конфиксация;
Г) суффиксация.

**Татар һәм рус телләрендә килешләр тәрҗемә иткәндә тәңгәл киләме?**
А) юк, килми
Б) һәрвакыт туры килә;
В) төрле очракта төрлечә;
Г) кайбер килешләр туры килми.

**Рус телендә күплек сан нинди чаралар ярдәмендә белдерелә?**
А) күплек сан кушымчалары, басым үзгәрү, суффикслар;
Б) килеш кушымчалары, супплетивизм, интонация;
В) кушымчалар, форма ясагыч суффикслар, супплетивизм, басым үзгәрү.

**Исем сүз төркеменә ничә грамматик категория хас?**
А) татар телендә ике, рус телендә дүрт;
Б) татар телендә дә, рус телендә дә дүрт;
В) татар телендә биш, рус телендә дүрт.

**Рус телендә <u>галифе, Тбилиси, мадам, Ландыш, Черных</u> сүзләре килеш белән төрләнешкә бәйле кайсы төркемгә карый?**
А) 1 склонение;
Б) төрле төрләнешле;
В) төрләнмәүче.

**Татар һәм рус телләрендә рәвешләр ясалуның продуктив ысуллары бармы?**
А) әйе, бар;
Б) рус телендә генә бар;
В) татар телендә генә бар;
Г) юк.

**Рус һәм татар телләрендә сыйфат сүз төркеме төрләнәме?**
А) әйе, төрләнә;
Б) юк, төрләнми;
В) рус телендә төрләнә, татар телендә өлешчә.

**Татар һәм рус телләрендә кисәкчәләр нәрсәгә нигезләнеп бүленә дип саныйсыз?**
А) нинди сүз янында килүенә карап;
Б) җөмләдәге урынына карап;
В) модаль мәгънәсенә карап.

## Тема: Татар һәм рус телләрендә фигыль

**Рус телендә фигыльләргә хас универсаль грамматик категорияләрне күрсәтегез**

А) вид, юнәлеш, зат-сан;

Б) заман, род;

В) юнәлеш, вид.

**Татар телендә фигыльләргә хас универсаль грамматик категорияләрне санагыз**

А) дәрәҗә, юнәлеш, заман;

Б) дәрәҗә, юнәлеш, барлык-юклык;

В) барлык-юклык, зат-сан, заман, дәрәҗә.

**Татар теле фигыльләренә генә хас грамматик категорияләрне күрсәтегез**

А) барлык-юклык, дәрәҗә;

Б) дәрәҗә, юнәлеш;

В) заман, төркемчә.

**Рус теле фигыльләренә генә хас грамматик категорияләрне күрсәтегез**

А) вид, юнәлеш;

Б) род, зат-сан;

В) вид, род.

**Татар һәм рус телләренә хас универсаль наклонениеләрне (төркемчәләрне) күрсәтегез.**

А) хикәяләү, шартлы теләк;

Б) боерык, шарт, теләк;

В) хикәяләү, боерык, шартлы теләк.

**Татар һәм рус телләрендә хикәя фигыльгә хас уникаль категорияләрне күрсәтегез.**

А) татар телендә дәрәҗә, барлык-юклык, рус телендә вид, род;

Б) татар телендә дәрәҗә, зат-сан, рус телендә вид, юнәлеш;

В) татар телендә дә рус телендә андый категорияләр юк.

**Татар телендә фигыльнең ничә төрләнеш тибы бар?**

А) өч;

Б) ике;

В) бер.

**Рус телендә фигыльләр төрләнеш үзенчәлегенә карап ничә типка бүленә?**

А) ике;

Б) өч;

В) җиде.

**Тема: Татар һәм рус телләре синтаксисы**

**Тезүле бәйләнеш татар һәм рус телләренең икесенә дә хасмы?**

А) әйе;

Б) юк;

В) рус теленә генә хас.

**Ияртүле бәйләнеш булганда, татар һәм рус телләрендә компонентлар**

А) берсе икенчесенә буйсына;

Б) тигез хокукта килә.

**Татар һәм рус телләрендә хәбәрлекле мөнәсәбәт кайсы очракта була?**

А) ияртүле бәйләнеш булганда;

Б) тезүле бәйләнеш булганда.

**Татар һәм рус телләрендә синтаксик чараларга бәйле ияртүле бәйләнешнең нинди төрләре бар?**

А) ярашу, башкарылу, янәшәлек;

Б) ярашу, хәбәрлекле, төгәлләүле;

В) аныклаулы, төгәлләүле, башкарылу.

**Структур-семантик кисәкләр ул -**

А) предикат, субъект, объект, атрибут, квалификатор;

Б) хәбәр, ия, тәмамлык, хәл, аергыч.

**Тулысынча ярашу татар теленә дә, рус теленә дә хасмы?**

А) әйе;

Б) юк.

**Татар һәм рус телләрендә компонентлар арасындагы мәгънә мөнәсәбәтенә карап сүзтезмәләр нинди төрләргә бүленә?**

А) ирекле һәм фразеологик;

Б) ирекле яки бәйле;

В) гади һәм катлаулы.

**Логик-грамматик кисәкләр ул -**

А) предикат, субъект, объект, атрибут, квалификатор;

Б) хәбәр, ия, тәмамлык, хәл, аергыч.

**Синтагматик кисәкләр ул –**

А) мәгънәви-интонацион буыннар;

Б) җөмләнең актуаль кисәкләргә бүленеше.

## ИМТИХАН ӨЧЕН ЯКЫНЧА СОРАУЛЫК

1. Рус-татар һәм татар-рус телләрен чагыштырма планда өйрәнү тарихы (кыскача гомуми күзәтү).

2. Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләрен) курсы, аның эчтәлеге, күләме һәм бурычлары.

3. Телләрне чагыштырма өйрәнү һәм тәрҗемә.

4. Рус-татар һәм татар-рус телләренең фонетик системаларын чагыштырма планда өйрәнү мәсьәләсе.

5. Татар һәм рус телләренең сузык авазлар системасы.

6. Чагыштырыла торган телләрдә редукция күренеше.

7. Татар һәм рус телләренең тартык авазлар системасы.

8. Чагыштырыла торган телләрдә тартык авазларга бәйле аваз закончалыклары.

9. Татар һәм рус телләрендә басым.

10. Татар һәм рус телләрендә иҗек төзелеше.

11. Татар һәм рус телләрендә сүз ясалыш ысуллары.

12. Чагыштырыла торган телләрдә сүз ясалыш мәгънәсе, моделе, тибы, чылбыры һәм оясы.

13. Татар һәм рус лексикографиясе: тарихы һәм бүгенге торышы.

14. Татар һәм рус телләренең орфографик принциплары.

15. Рус телендә төрки-татар алынмаларының үзләштерелеше.

16. Татар теленә рус теленнән һәм рус теле аша кергән сүзләр. Аларның фонетик, лексик-семантик һәм морфологик үзләштерелүе.

17. Татар һәм рус телләрендә сүзләрне төркемләү принциплары, сүз төркемнәре.

18. Татар һәм рус телләрендә исем.

19. Татар һәм рус телләрендә килешләр: уртак, охшаш һәм аермалы яклар.

20. Татар һәм рус телләрендә фигыль.

21. Рус фигылендәге вид категориясенең татар телендә бирелеше.

22. Татар һәм рус телләрендә фигыль сүз төркеменә хас универсаль категорияләр.

23. Татар һәм рус телләрендә фигыль сүз төркеменә хас уникаль категорияләр.

24. Татар һәм рус телләрендә сыйфат.

25. Чагыштырыла торган телләрдә исем һәм сыйфат сүз төркемнәренең кулланылыш үзенчәлекләре.

26. Татар һәм рус телләрендә рәвеш.

27. Татар һәм рус телләрендә предикатив сүзләр.

28. Татар һәм рус телләрендә сан.

29. Татар һәм рус телләрендә алмашлык.

30. Татар һәм рус телләрендә бәйләгеч сүз төркемнәре.

31. Татар һәм рус телләрендә модаль мәгънәле сүзләр.

32. Татар һәм рус телләрендә аваз ияртемнәре.

33. Татар һәм рус телләрендә җөмләнең баш кисәкләре.

34. Татар һәм рус телләрендә җөмләнең иярчен кисәкләре.

35. Татар һәм рус телләрендә сүзләр бәйләнеше.

36. Татар һәм рус телләрендә сүз тәртибе.

37. Татар һәм рус телләрендә гади җөмләләр.

38. Татар һәм рус телләрендә кушма җөмләләр.

39. Чагыштырыла торган телләрдә күп иярченле һәм катнаш кушма җөмләләр.

40. "Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы. Аның татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүдә роле.

41. 2004 – 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы (2004) кабул ителү. Аның татар һәм рус телләрен чагыштырып өйрәнүдә роле.

42. Җәмгыятьтә икетеллелек, күптеллелек мәсьәләләре һәм аларга ирешүдә телләрне чагыштырып өйрәнүнең роле.

## КУРСНЫ ӨЙРӘНҮНЕ ОЕШТЫРУГА КАРАТА МЕТОДИК КҮРСӘТМӘЛӘР

*Укытучы өчен методик күрсәтмәләр.* “Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләре)” курсы *050302 “Туган (татар) тел һәм әдәбият”* белгечлеге буенча өйрәнелә торган лингвистик фәннәрнең иң соңгыларыннан буларак, студентларның татар һәм рус телләре өлкәсендәге белем һәм күнекмәләренә таянып укытуны күздә тота.

Әлеге курс студентларны лингвистик терминология белән коралландыруны, чагыштырма тел белеме өлкәсендәге төп юнәлеш һәм мәктәпләр белән таныштыруны, татар һәм рус телләрен өйрәнү һәм анализлау методларын өйрәтүне дә максат итеп куя.

Программада татар грамматикасы традицияләре саклану белән беррәттән яңа хезмәтләргә дә игътибар итү күз алдында тотыла. Тел белемендә тулаем расланмаган, яки гомум кабул ителмәгән мәсьәләләргә карата укытучы альтернатив төстә үз фикерләрен аудиториягә җиткерә.

“Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләре)” курсының төп теоретик материалы лекцияләрдә бирелә: чагыштырыла торган телләрнең типологик характеристикаларына таянып, телнең барлык ярусларына да

кагылышлы универсаль, специфик һәм уникаль үзенчәлекләре хакында фәнни фикерләр тасвирлана.

Өйрәнелә торган теоретик материалны ныгыту, студентларның лингвистик фикерләү сәләтен һәм тел фактларын анализлау осталыкларын үстерү максатында, семинар дәресләр үткәрелә, көндәлек сөйләм теленнән, газета-журналлардан, теле-, радиотапшырулардан, матур әдәбияттан һ.б алынган фактик материал анализлана. Бу очракта мәктәп һәм югары уку йорты программаларының үзенчәлекләре дә игътибарда тотыла.

Дәресләрне алып баруда такта, схемалар, таблицалардан, “Чагыштырма тел белеме” курсы өчен төзелгән үрнәк программадан, сүзлекләрдән, курста карала торган темаларга кагылышлы монографияләрдән файдаланыла.

Курсны өйрәнү барышында студентларның язма һәм сөйләмә рәвештә биремнәр үтәве, докладлар белән чыгышлар ясавы да күздә тотыла. Мөстәкыйль эш буларак, студентларга реферат язу өчен библиографиядә күрсәтелгән кайбер фәнни хезмәтләрне тәкъдим итәргә мөмкин. Болар барысы да әлеге курсны үзләштерергә ярдәм итәчәк. Материалны үзләштерү дәрәҗәсен тикшерүнең шактый продуктив алымы буларак тестлар үткәрү уңышлы.

Студентларның “Чагыштырма тел белеме (татар һәм рус телләре)” курсын үзләштерү дәрәҗәсе имтихан ярдәмендә ачыклана. Семестр дәвамында семинар һәм гамәли дәресләрдә җаваплар, гомумән, дәрескә йөреш, тест нәтиҗәләре әлеге имтиханда билге куйганда исәпкә алынырга тиеш.

*Студентлар өчен методик күрсәтмәләр*. “Чагыштырма тел белеме” курсы 10 семестрда 20 сәгать лекция, 16 сәгать гамәли дәрес, мөстәкыйль эшләр өчен 36 сәг. күләмендә планлаштырылган. Үзләштерелгән белем имтихан ярдәмендә бәяләнә.

Мөстәкыйль сәгатьләрдә студентлар:

- темаларга кагылышлы теоретик материалны үзләштерә, ныгыта;
- тәкъдим ителгән төп һәм өстәмә әдәбиятны укый;
- исемлектә күрсәтелгән һәм башка темаларга материал әзерләп, семинар дәресләрдә чыгыш ясый;
- татар һәм рус телләре материалы нигезендә чагыштырма фонетик, сүз төзелеше һәм грамматик анализлар ясый;
- күрсәтелгән темаларны мөстәкыйль үзләштерә;
- анализ ясау өчен фактик материал туплый;
- курс эшләре башкара.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ

*а) төп әдәбият*

Җамалетдинов Р.Р. Татар һәм рус телләренең чагыштырма грамматикасы: Дәреслек-кулланма. – Казан: КДУ, 2004 – 142 б. (Педагогик белгечлекләр буенча УМО грифы белән).

Закиев М.З., Сафиуллина Ф.С., Зиннатуллина К.З., Ибраһимов .М. Сопоставительный сиинтаксис русского и татарского яыков. – Казань: Татар.кн.изд-во, 2007.

Салимова Д.А. Части речи: история изучения и вопросы классификации. Учебное пособие. – Казань: Школа, 2004. – 216 с.

*б) өстәмә әдәбият*

Аминова А.А. Производный глагол в сопоставительном аспекте: На материале русского и татарского языков. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993.

Ахунзянов Э.М. Контрастивная грамматика: Морфология русского и тюркских языков: Учебное пособие. — Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1987.

Байрамова Л.К. Сопоставительный синтаксис русского и татарского языков. — Зеленодольск: Дело, 1997.

Валгина Н.С., Розенталь Д.Э., Фомина М.И. Современный русский язык / Под ред. Н.С.Валгиной: Учебник для вузов. – Изд. 6-е, перераб., и доп. – М.: Логос, 2003. – 528 с.

Газизов Р.С. Сопоставительная грамматика татарского и русского языков. Перераб. и доп. изд. — Казань: Татарское кн. изд-во, 1966.

Кульшарипова Р.Э. Сопоставительная фонетика русского и татарского языков: Учебно-методическое пособие для студентов-филологов. — Казань: УНИПРЕСС, 1998.

Методы сопоставительного изучения языков. – М.: Наука, 1988.

Нурмөхәммәтова Р.С. Тәрҗемә белеменең теоретик нигезләре. – Казан: Вестфалика, 2010. – 164 б.

Русская грамматика. В 2-х т. Т. I. Фонетика. Морфология. Т. II. Синтаксис. — М.: Наука, 1980.

Сафиуллина Ф.С. Ике телне чагыштырып укыту // Мәгариф. — 1996. — №6.

Сафонова С.С. Лекции по современному русскому языку (словообразование, морфология, синтаксис): Учебное пособие для студентов тюркоязычных отделений педвузов. – Казань: Изд-во ТГГПУ. – 2008. – 198 с.

Современный русский литературный язык: Учебник / П.А.Лекант, Н.Г. Гольцова, В.П.Жуков и др.; под ред. П.А.Леканта. – 3- изд., испр., и доп. – М.: Высш.шк., 1996. – 462 с.

Сопоставительное словообразование русского и татарского языков / Сост. Фатхутдинова В.Г. – Казань: Изд-во Казан. ун-та, 1993.

Татар грамматикасы. Өч томда. 1 т. / Ред.кол. М.З.Зәкиев, Ф.А.Ганиев, К.З.Зиннәтуллина. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1998. – 512 б.

Татар грамматикасы. Өч томда. 2 т. / Н.Б.Борһанова, Ф.А.Ганиев, М.З.Зәкиев һ.б. - Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 2002. – 448 б.

Татар грамматикасы. Өч томда. 3 т. / М.З.Зәкиев. – Мәскәү: Инсан, Казан: Фикер, 1999. – 512 б.

Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы // Татарстан Республикасы дәүләт телләре һәм Татарстан Республикасында башка телләр турында Татарстан Республикасы Законы. 2004 – 2013 елларга Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Респбуликасында башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү буенча Татарстан Республикасы дәүләт программасы. - Казан: Татар.кит.нәшр., 2005. - 69 б.

Тумашева Д.Г. Хәзерге татар әдәби теле. Морфология. – Казан: КДУ нәшр., 1978.

Харисов Ф.Ф. Основы методики обучения татарскому языку как неродному. – СПб, 2002.

Харисова Ч.М. Хәзерге татар әдәби теле морфологиясеннән лекцияләр. — Казан, 2006. – 148 б.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

**Эчтәлек**


Кереш……………………………………………………………….. 3

Курсны өйрәнү өчен якынча тематик план……………………...……… 4

Лекцияләр һәм гамәли дәресләр өчен темалар ……………………... 4

Чагыштырма аспектта теоретик материал………………..…………… 11

Чагыштырма аспектта анализ үрнәкләре………………………….... 44

Белемнәрне тикшерү өчен тестлар……………………………........... 48

Имтихан өчен якынча сораулык……………………..………………… 53

Курсны өйрәнүне оештыруга карата методик күрсәтмәләр ……..... 55

Әдәбият исемлеге…………………………………………………… 56

**Сопоставительное языкознание**
(на материале татарского и русского языков)

*Учебно-методическое пособие*
*для студентов высших учебных заведений*
(на татарском языке)

Составитель:

**Саттарова** Мадина Рашидовна

Подписано в печать ____________
Формат бумаги 60 X 84  1 / 16 Бумага офсетная
Усл.п.л. ___ Уч.-изд.л. ___
Тираж Заказ